МАРАТ КӘБИРОВ: «Мин үземне урманда, агачлар арасында сыман хис иттем...»

> 4

МӨЛДЕРӘМӘ КҮҢЕЛ Миләүшә Гайфуллинаның тормышында уттан алып суга сала торган чаклар күп була

> 4

ИЛГИЗ МӨХЕТДИНОВ: «Өч хәрефле генә сүз, ә эчтәлеге, мәгънәсе бик киң»

> 5

КАМИЛЛЕККӘ ОМТЫЛУ «ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 110 (29077) | Чәршәмбе | 2 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Эльвира ВӘЛИЕВА

КҮПЕР САЛУНЫҢ ҖАЕ БАР

Хәерле юл!

Татарстанда 400гә якын күпер тузган. Узган елдан бирле әлеге төр корылмаларны «Куркынычсыз имин юллар» илкүләм проекты кысасында да төзекләндерәләр. Былтыр республикадагы 33 күперне рәткә китергәннәр инде. Быел исә тагын 44ендә юлчылар эшли. Аларның алтысы әзер. Яңа күперләрдән «ВТ» хәбәрчесе дә йөреп кайтты.

Автор фотосы

– Төзелеш барышын күзәтеп кенә тордык, чөнки безгә яңа күпер бик тә кирәк иде, – ди Яшел Үзән районының Норлат авылында яшәүче Хәмзә Идиятуллин. – Искесе шактый таушалган булу – бер хәл, ул уйсулыкта урнашканлыктан, юлы да бик текә иде. Шуңа күрә бу урында элек-электән аварияләр күп булды. Яңа күпер исә бөтен куркынычсызлык таләпләренә җавап бирә.

Төрләмә – Норлат – Борындык автомобиль юлындагы Булатка елгасы аша салынган әлеге күпер – «Куркынычсыз имин юллар» илкүләм проекты кысасында төзекләндерелгән корылмаларның берсе. Билгеле булганча, илкүләм проект Россия Президенты Владимир Путин тәкъдиме белән 2019 елдан бирле тормышка ашырыла. Моңа кадәр, 2017–2018 елларда, илнең кайбер төбәкләрендә, шул исәптән Татарстанда «Куркынычсыз һәм имин юллар» өстенлекле федераль проекты гамәлдә иде. Узган елдан башлап аның кысасында күперләрне дә рәткә китерәләр. Ничек кенә әле! Төзелеш барышында моңарчы тиңе булмаган технологияләр кулланыла. Йөз кат сөйләгәнче, бар кат күрүең яхшырак, ди. Яңа күперләрне журналистларга да күрсәттеләр.

– Кечкенә дә төш кенә, – ди Булатка елгасы аша салынган күпер турында биредәге төзелеш өчен җаваплы «Каздорстрой» оешмасының эшләрне башкаручысы Руслан Шәрәфетдинов. – Бу юл бик тә әһәмиятле. Ул М7 автомобиль трассасына алмаш булып тора. Чөнки биредән Кайбыч районының Борындык авылы аша Ульян юлы киселешеннән М7 трассасына чыгарга мөмкин. Зур юлда ул-бу булып, «бөке» җыелса, халык биредән йөри. Күпердәге куркынычсызлыкны арттыру максатыннан, аны элеккегесеннән биш метрга югарырак күтәрттек. Хәзер ул җир өстеннән тугыз метр биеклектә уза. Биек баганалар утыртмас өчен, күпер махсус коеп ясалган нигезгә утыртылды. Хәзер елга озын тоннель аша ага.

Яңа күпернең үзенчәлеге дә бар. Баксаң, язгы ташу вакытында яки яңгырдан соң юлдан аккан пычрак су туп-туры елгага коймый. Ул улаклар аша махсус коега эләгә. Биредә таш, ком һәм химик катнашмалардан чистартыла. Шуннан соң гына җыелган су елгага кушыла.

– Мондый технологияләр яңа күперләр төзелеше барышында гына кулланыла, – дип аңлатты Руслан Шәрәфетдинов.

Норлат авыл җирлеге башлыгы Илдус Саттаров әйтүенчә, аларга сигез авыл һәм биредә яшәүче 3 меңнән артык кеше карый. Норлатта гына да 1,6 мең чамасы кеше яши. Бирегә күрше-тирә авыллардан балалар укырга йөри.

– Шуңа күрә юл ул – тормышның дәвамы дигән сүз. Аның куркынычсызлыгы да бик мөһим, – ди җирлек башлыгы.

Яшел Үзән районындагы Бәллүр елгасы аша да яңа күпер салганнар. Җиде меңнән артык кеше яшәүче Карамалы Тау бистәсен икегә бүлгән бу юлның әһәмияте көн кебек ачык.

– Иске күпер бик нык тузган иде. Җәй көне Бәллүр елгасы кибә. Ә язгы ташулар вакытында бигрәк тә куркыныч бу юл. Елга аша чыкканда, күпер генә җимерелмәсен дип, кот очып йөрдек. Яңасын бик тиз төзеделәр. Минем машинам юк. Кирәк җиргә велосипедта барам. Хәзер безгә җәяүле юлы да салдылар. Бәллүребез чын бәллүргә әйләнде, – ди авылда яшәүче Людмила Савельева.

«Каздорстрой» оешмасы прорабы Рамил Бикмуллин әйтүенчә, яңа күпер искесеннән күпкә чыдамлырак та әле.

– Мондый корылмалар төзегәндә, гадәттә әзер горизонталь терәкләр кулланыла. Биредә исә алар урында ук махсус коеп эшләнде. Биш урынына сигез терәк куйдык, – ди белгеч. – Күпер экологик таләпләргә җавап бирә. Куркынычсызлыкны арттыру өчен, авыл эченнән узучы юлны турайттык та әле.

Яңа күперләрнең бәяләре дә билгеле. Бәллүр елгасы аша салынган корылма якынча 45 миллион сумга төшсә, Булатка елгасы аша төзелгәне исә 83 миллион сум чамасы тәшкил иткән.

«Юллар да, күперләр дә төзекләндерелә»

Артем ЧУКИН, Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары:
– Татарстанда транспорт инфраструктурасын үстерү юнәлешендә шактый эш башкарыла. Бүген М12 төзелеше, М7не реконструкцияләү кебек зур проектлар тормышка ашырыла. Алар белән беррәттән, төбәк дәрәҗәсендәге юллар да төзелә һәм төзекләндерелә. «Куркынычсыз имин юллар» илкүләм проекты кысасында гына да 2017 елдан бирле меңәрләгән чакрым юл яңартылды. Быел тагын 27 чакрым юл салу күздә тотыла. Узган елдан бирле илкүләм проект кысасында күперләр дә төзекләндерелә. Быел гына да бу максаттан 3 миллиард сумнан күбрәк акча тотылачак. Төбәк әһәмиятендәге зур күперләр, мәсәлән, Ютазы районындагы Димескәй елгасы аша озынлыгы 96 метрга җиткән корылмаларны рәткә китерү белән беррәттән, авыллар эчендәге кечкенә күперләр дә төзекләндереләчәк.

Тагын арта

1 августтан эшләүче пенсионерларның пенсиясе арта. Моның өчен гариза тапшырырга кирәкми. Россия Социаль фондының Татарстан буенча бүлеге хәбәр иткәнчә, республикада 250 меңнән артыграк кешенең пенсия күләме үсәчәк, дигән сүз.

Картлык яки инвалидлык буенча пенсиягә чыгып, «ак» хезмәт хакы алып (мондыйлар өчен иминият кертемнәре түләнә) эшләүчеләргә кагыла бу. Шулай ук туендыручысын югалту буенча пенсия күләме дә арта.

Фонд бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин аңлатып үткәнчә, пенсиягә өстәмә хезмәт хакының күләменә бәйле. Эшләүче пенсионерларның хезмәт хакы да, аларга эш бирүче түли торган иминият кертеме дә төрлечә. Шуңа күрә өстәмә күләме һәркемгә дә бер үк төрле түгел. Иң зур күләме 372,31 сум тәшкил итәчәк.

Моннан тыш 1 августтан пенсия тупланмасы да арта. Монысы эшләүгә генә түгел, бәлки идарәче компанияләрнең акчаны инвестицияләвенә дә бәйле. Тупланма күләме 10 процентка үсәчәк.

Керү тыела

Татарстанда янә кайбер урманнарга керүне чиклиләр. Премьер-министр Алексей Песошин бу җәһәттән карарга кул куйган. Документ хокукый мәгълүматлар рәсми порталына урнаштырылган.

Чикләү урманнарда IV класслы куркыныч вазгыять урнашуга бәйле. Шулай итеп, Аксубай, Әлки, Әлмәт, Арча, Баулы, Биләр, Болгар, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Кайбыч, Кызыл Йолдыз һәм башка шундый урманчылык биләмәләренә баруга 21 көнгә чикләү кертелә.

Документта урманнарга җәяүләп яки машинада керүне һәм нәрсәдер эшләүне чикләү күздә тотылган. Бары тик урманчылык өлкәсендә эшләүчеләргә генә кагылмый бу. Карарның гамәлдә булу чорына урман юлларына шлагбаумнар урнаштырылып, тәүлек әйләнәсе дежур тору оештырылачак.

Тиздән башлана

Быел Татарстанда 57 меңнән артыграк бала тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлап керергә җыена. Мәгариф һәм фән министрлыгы матбугат хезмәте хәбәренә караганда, 1 сентябрьдән республикада барлыгы 511 меңнән күбрәк укучы парта арасына утырачак. Узган елда исә республика мәктәпләрендә балалар саны 486 мең 615 булган.

Министрлыкның Гомуми мәгариф идарәсе башлыгы Татьяна Алексеева әйтүенчә, Татарстанда соңгы 5 ел эчендә беренче сыйныфка баручы балалар 7 меңгә арткан. Укучылар саны ишәю сәбәпле, яңа уку йортларын төзү дәвам итә. Әле күптән түгел генә Казанның «Салават Күпере» торак комплексында яңа мәктәп төзеләчәк. Ул тагын 1,5 мең баланы үзенә сыендырачак. Бу максатка республика бюджетыннан 934 миллион 521 мең сум акча бирелә.

Барыбер түләтәләр

Татарстанның суд приставлары июль аенда ЮХИДИ штрафларын түләмәүчеләрдән барлыгы 34,3 миллион сум бурыч җыеп алган. Суд приставлары федераль хезмәтенең республика буенча Баш идарәсе матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, приставлар бурычлыларга карата, банк счетларына арест салудан башлап, шәхси мөлкәтен тартып алуга кадәр, төрле чаралар күрә. Тәҗрибә күрсәткәнчә, мондыйларны автомобильдән мәхрүм итү иң нәтиҗәле чара булып тора. Бик күпләр, суд приставларының машинага арест салырга җыенуларын белүгә үк, штрафларын түләргә ашыга.

Казанда инспекторлар белән уртак рейд барышында бурычлы 7 йөртүче туктатылган. Бишесе шундук барлыгы 136 мең сум күләмендә әҗәтен түләгән. «Лада» хуҗасы, машинасыннан коры калмас өчен, берьюлы 51 мең сумын чыгарып салган. Урында түли алмаулары сәбәпле, икесенең транспорт чарасын алырга туры килгән. Hyndai машинасы хуҗасы ЮХИДИгә 495500 сум штраф түләмәгән өчен иномаркасыннан мәхрүм калган.

kukmor-rt.ru

Яңалык

Төймә генә коткармый

Мәктәп һәм балалар бакчаларында кизү торучы сакчыларны террорчыларга каршы торырга өйрәтәчәкләр. ГОСТ таләпләренә шундый үзгәреш кертергә җыеналар. Аның проекты әзер инде.

Әлеге документны эшләгәндә, чит ил тәҗрибәсе дә исәпкә алынган. Проект авторлары фикеренчә, сакчыларның әзерлегенә игътибар арту белем бирү оешмаларында килеп чыккан фаҗигале очракларны да булдырмый калыр иде.

Дөрес, мәктәп һәм балалар бакчаларында эшләүче сакчыларга мондый таләп әле дә куела. Әмма күп очракта ул кәгазьдә генә кала. Росстандарт идарәсе башлыгы Антон Шалаев сүзләренә караганда, яңа проект сакчыларга куелган әнә шул таләпне катгыйландыруны күздә тота да инде. Яңа ГОСТ таләпләре гамәлгә кергәч, мәктәп һәм балалар бакчаларында эшләүче сакчыларның эше коткару төймәсенә басу белән генә чикләнмәячәк дип ышандыралар. Аларга кораллы һөҗүм итүчеләргә каршы торырга мөмкинлек биргән махсус күнекмәләр өйрәтәчәкләр. Алар бу осталыкларын автомат рәвештә эшләрлек дәрәҗәгә җиткерергә тиеш булачак.

– Белем бирү оешмаларында сакны көчәйтергә кирәк. Бигрәк тә хәзерге вазгыятьтә. Мондый чакта гадәттән тыш хәл килеп чыгу ихтималы бермә-бер арта бит. ГОСТка таләпләр әнә шундый фаҗигаләрне алдан кисәтү максаты белән кертелә дә инде, – ди Антон Шалаев.

Казанның Совет районындагы бер мәктәптә сакчы булып эшләүче Зариф Гарипов бу үзгәрешнең бик нәтиҗәле булачагына ышанып бетми.

– Яшерен-батырын түгел, бүген мәктәп, балалар бакчаларында, нигездә, лаеклы ялдагы, өлкән яшьтәге абый-апалар эшли. Араларында хәтта әби-бабайлар да

Илдар Мөхәммәтҗанов

бар. Шулай булмый ни, ул хезмәт хакына тагын кем риза булып килсен! Өлкәнрәк кеше, ул-бу була калса, махсус төймәгә баса алыр, шикләнмим. Әмма ниндидер күнекмәләр ярдәмендә һөҗүмчегә каршы торырга аның көче дә, егәре дә җитмәячәк, билгеле. Шуңа күрә белем оешмаларында куркынычсызлыкны көчәйтергә телиләр икән, иң элек эшне кадрларга тиешле шартлар тудырудан башларга кирәк, – ди ул.

Ата-аналар исә бу яңалыкның кертелүенә бишкуллап риза. Кызын Казанның 137 нче балалар бакчасына йөртүче Камилә Галиева яшерми: 175 нче гимназиядә булган фаҗигадән соң тынычлыгы югалган аның.

– Ул коточкыч хәлдән соң барлык ата-ана куркып калды инде. Балабызны бакчага, мәктәпкә илткәндә, аларны ышанычлы кулларга тапшырабыз дип ышанып барабыз бит. Шуңа күрә сакчыларның әзерлеген көчәйтергә җыенуларына бик сөенәм. Хәтта моның өчен ата-аналардан өстәмә акча җыйсалар да каршы килмәм, мөгаен, – ди ул.

Сүзгә-сүз

Валерий ЛИПСКИЙ, Россия Тикшерү комитетының Татарстан буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе:

Әлбәттә, 90 нчы еллар белән чагыштырганда, җинаятьчел төркемнәр саны кимеде. Без ул вакыттагы җинаятьчеләрне ачыклау белән әле дә шөгыльләнәбез. Быел без җинаятьчел төркемнәрнең 19 катнашучысына карата элегрәк кылынган 61 җинаять очрагы буенча эш ачтык. Бу – үтерү, акча таләп итү кебек гамәлләр.

(«Татарстан-24» каналына биргән интервьюдан)

РОССИЯДӘ – АКЧАНЫ САК ТОТУ

Илдә яшәүчеләрнең күпчелеге ремонтка һәм ялга акчаны азрак экономияли башлаган. Moneyman хезмәте шул хакта хәбәр итә.

2022 ел
32% >> ремонтны кичектергән
53% >> ялга акчаны азрак тоткан яисә ялдан баш тарткан
12% >> өстәмә эш эзли башлаган

2023 ел
24% >> ремонтны кичектергән
37% >> ялга акчаны азрак тоткан яисә ялдан баш тарткан
16% >> өстәмә эш эзли башлаган



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АКШ: АРМИЯГӘ ЫШАНЫЧ ЮК

Соңгы көннәрдә Африка иле Нигердагы кораллы фетнә тирәсендә киеренкелек көчәя. Гвинея гыйсъянчыларны рәсми рәвештә яклаган беренче ил булды. Нигерның күршеләре Буркина-Фасо һәм Мали, теләсә нинди хәрби тыкшыну аларга да сугыш игълан итүгә тиң, дип белдерделәр. Илдә агымдагы вазгыять шундый: түнтәрелгән Президент яклы сәясәтчеләр массакүләм рәвештә кулга алына, Агадес шәһәрендә урнашкан Америка хәрби базасындагы хәрбиләргә базадан читкә чыгу рөхсәт ителми. Президентны хәрбиләрдән азат итү максатыннан, Франциянең Нигерга һава һөҗүмнәре ясау ихтималы турында хәбәрләр таратылган иде, рәсми Париж аларны кире какты. Хәзергә Франциягә уран озату туктатылды. Һәр өченче француз йорты Нигердан алынган уран хисабына энергия һәм җылылык ала. 80 процент нигерлы исә электр энергиясеннән бөтенләй файдаланмый. Французларга энергия биреп, үзең аннан мәхрүм калу бик үк сөенечле хәл түгел инде. Африкада европалыларга каршы көрәш дулкыны көчәю аңлашыла торгандыр. Нигерда икътисадның бар тармаклары да чит ил кешеләренә буйсынган, хәтта илнең үз валютасы да юк. Аның өчен Көнбатыш Африка CFA франкын Франция Үзәк банкы баса.

АКШта әлегә яңа хакимиятләргә мөнәсәбәтләрен ачык белдермәделәр. Көнбатышлылар Нигерның яңа хакимиятләре Россия ягына авышыр дип куркалар. Майлы калҗаны кулдан ычкындырасылары килми. Хәрби хәрәкәтләр башласаң, югарыда әйтелгән илләр каршылык күрсәтергә җыена. Озакка сузылган интектергеч сугышка кереп китү перспективасы сөендерми.

Америкадагы сораштыру нәтиҗәләре халыкның АКШ кораллы көчләренә ышанычы кимүен күрсәтә. Бары тик 60 процент америкалы гына армиягә ышаныч белдерә икән. Бу – 1997 елдан соң иң түбән күрсәткеч. Вьетнам сугышы тәмамлангач, 1980 нче еллар башына кадәр америкалыларның армиягә ышанычы 50–58 процент булган. Фарсы култыгындагы 1991 елгы сугыштан соң ул рекордлы 85 процентка күтәрелгән. 2001 елның 11 сентябреннән соң да әле тотрыклы рәвештә 70 проценттан югарырак торган. Гыйрак һәм Әфганстаннан гаскәрләр чыгарылгач, ышаныч тагын кими башлаган. Җир шарында исә ресурслар өчен көрәш кискенләшә. Нигер – шуның бер мисалы.

Көнбатышта икътисадый кризис та дәвам итә. Европаның өченче икътисады булган Италия икенче кварталда тискәре нәтиҗәләр күрсәтә: түбәнәю – 0,3 процент. Танылган икътисад белгечләре АКШта облигацияләр базары җимерелү алдында торуын белдерә. Төп ставканы күтәрү бурычларны түләүне кыенлаштыра. Нефтькә бәяләр күтәрелү дә хәлне авырайта. Көнбатышны чимал белән тәэмин итеп торучы илләрдәге гыйсъянчылык хәрәкәтләре көчәюче кризис төенен кораллы көчләрсез генә чишү мөмкин түгел дигән нәтиҗәгә этәрә.

Россиядә

НЕФТЬ КЫЙММӘТЛӘНӘ. ДОЛЛАР ДА

Дөнья базарларында чимал бәяләре Россия өчен уңай зонада. Августтан Мәскәү «кара алтын» экспортын тагын 500 мең баррельгә киметте. Алдагы киметүгә китереп кушкач, җир маен чыгару миллион баррельгә кимергә тиеш. Гарәпләрнең дә Россиягә теләктәшлек белдерүләре баррельнең кыйммәтен 80 доллардан югарырак күтәрде. Россия нефте Көнбатыш куйган түшәм бәяне узып китеп сатыла, ди белгечләр. «Дошманнар» бу фронтта да оттыра, санкцияләрнең нәтиҗәлелеге кими. Ләкин базардагы уңышлар никтер илнең финанс хәленә уңай йогынты ясамый. Доллар атна башында 92 сумга җитте, евро да кыйммәтләнә. Нефтьчеләр валютаны Россиягә кайтармый, офшорларда яшерә. Дүшәмбе Путин хөкүмәтара килешүләр нигезендә товар сатучыларга валюта керемен чит илдә калдырырга рөхсәт иткән указга имза салды. Февраль аенда экспортчылар биржада мәҗбүри рәвештә валюта сатудан Президент рөхсәте белән азат ителгәннәр иде инде, әмма акча Россия счетларында сакланырга тиеш иде. Соңгы таләп йомшартылды, хәзер валютаны чит ил банкларында да калдырырга мөмкин. Барлык экспорт өчен дә түгел бу кагыйдә. Хөкүмәтара килешүләр нигезендә сатылган товарларга гына карый. Газ тулысынча диярлек шундый килешүләр белән сатыла. Нефтьнең дә байтагы шулай. Безнең кебек кара кешегә указның асылы-файдасы аңлашылмый, акча илгә кайтса һәм үзебезнең икътисадка эшләсә, яхшырак дип беләбез. Путин киңәшчеләре, Президентка имза салу өчен документ төрткәндә, эшнең асылын безгә караганда яхшырак беләләрдер, дип уйлыйк. Без бит, мәсәлән, үсеп килүче илләрнең дистәләгән һәм йөзләгән миллиард доллар әҗәтен кичергәндә дә, мокытларча: «Акча үзебезгә дә зыян итмәс иде», – дип уйлыйбыз. Ил күләмендә әнә торак-коммуналь хезмәтләр өчен әҗәтләр генә дә 900 миллиард сумга якынлашкан. Аларны беркем дә кичерергә җыенмый. Әмма зур сәясәт тәгәрмәчен зур түрәләр әйләндерә, алар мантыйгы безнекенә туры килми.

Валюта кыйммәтләнү импорт товарлар бәясен күккә чөя. Без күбрәк шул хакта уйлыйбыз. Автозапчастьлар әнә ел башыннан 20–40 процентка кыйммәтләнгән инде, ел ахырына тагын 20–25 процент өстәр, диләр. Башка товарлар белән дә хәл шулайрак инде.

Валюта кыйммәтләнү безнең хезмәт хакларының һәм пенсияләрнең доллардагы күләмен дә кечерәйтә. Россия БДБ илләре арасында пенсияләре һәм хезмәт хаклары зуррак ил буларак йөри иде. Хәзер лидерлык тәмамлана. Казахстанда пенсиянең уртача күләме – 270 доллар, Азәрбайҗанда – 249, Россиядә – 248 генә. Дөрес, шөкер итәргә урын күп әле. Үзбәкстанда уртача пенсия – 97 доллар, Молдовада – 58, Таҗикстанда – 27. Акчаны уңга-сулга өләшеп, бурычларны кичереп яшәсәк, Үзбәкстан пенсиясе кадәр генә ала башламабызмы яисә Таҗикстан хәлендә калмабызмы икән?

БУЛГАННЫ САКЛАП ТОТЫЙК



«Татар-информ»

Әйләнә-тирә

Татарстанда 631 төр хайван һәм үсемлек юкка чыгарга мөмкин. Аларны 2025 елда дөнья күрәчәк дүртенче Кызыл китапка кертәчәкләр. Хайваннар һәм үсемлекләрне саклап калу өчен, республикада 193 махсус саклана торган территория бар. Быел алар алтыга артачак. Бу хакта Министрлар Кабинетында узган брифингта Татарстанның Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе Федор Батков сөйләде.

– Безнең белгечләр даими эзләнүдә. Республиканың 17 районында Татарстанда сирәк очрый торган хайван һәм үсемлекләргә тап булдык. 2019 елдагы эзләнүләр 15 төрле хайван һәм гөмбәне саклап калырга ярдәм итте. Хәтта 50 ел буе күренмәгән үсемлекләр килеп чыга. Без аларны Кызыл китапка керттек, – ди ул. – Кызыл китапның беренчесе 1995 елда басылып чыккан иде. Һәр ун ел саен аны үзгәртеп бастырабыз. Анда 226 төр хайван һәм 318 төр үсемлек, 87 төр гөмбәне кертәчәкбез. Китапны яңадан бастыру 10 миллион сумга төшәчәк.

Кызыл китапка кертеләчәк хайван һәм үсемлекләр

- **11** төр балык
- **108** төр умырткасызлар
- **318** төр үсемлек
- **24** төр лишайник
- **33** төр имезүчеләр
- **67** төр кош
- **4** төр сөйрәлүче
- **3** төр амфибия
- **63** төр гөмбә

Яңа Кызыл китаптан көрән аюны сызып атачаклар. Баксаң, соңгы елларда аларның саны арткан. Кайчандыр берничә генә калган була алар. Хәзер исә ел саен безнең республикада 60лап аю санныйлар икән. Ә инде күчеш вакытында аларның саны 140ка җитә.

– Саны артып киткән дию аларны атарга ярый дигән сүз түгел. Аюлар Саба, Теләче, Мамадыш, Арча, Биектау, Тәтеш районнарында еш очрый, – ди Федор Батков.

Сүз уңаеннан, ул, аю очраганда, ничек сакланырга икәнлеген дә аңлатты.

– Аю – бик куркак җанвар. Шуңа күрә урманда шаулап йөрегез. Аюны күрүгә, тавышланырга, кулыгызны өскә күтәрергә, берәр киселгән агачка басарга кирәк. Аю сезне үзеннән зур итеп тойсын. Кулчатырны ачып җибәрү дә аюны куркыта икән, – ди ул.

Белгечләр, хайван һәм үсемлекләрне махсус территорияләр булдырып саклап калабыз, диләр. Федор Батков әйтүенчә, әлеге территорияләр 5 ел элек кенә комитетка тапшырылган. Әнә шул вакыт эчендә 13 махсус саклана торган территория төзелгән. Бу республика мәйданының 7 процентын алып тора. Биш ел эчендә мондый урыннар 20 процентка арткан. Башкалар да сакчыл карасын, бу хакта белеп торсын өчен, комитет вәкилләре экологик чаралар да уздыра икән. Бер ел эчендә 1500 шундый очрашулар узган. Анда 30 меңнән артык кеше катнашкан. Федор Батков сүзләренчә, бары тик экологик тәрбия алып барып кына, табигатьне саклап була.

Комитет белгечләре, балаларга аңлату, күрсәтү өчен, 5 табигать заказнигында «экологик сукмак» оештырганнар. Шул рәвешле, кечкенәдән балалар күңеленә табигатькә карата мәхәббәт уятып, сакчыл булырга өйрәтәләр.

Комитет рәисе тыюлыкларда сак булырга, табигатькә зыян салмаска, анда үскән агач һәм үсемлекләргә кагылмаска куша. Ботагын да сындырырга ярамый. Моның өчен административ җаваплылыкка тарталар.

Үзләре яшәгән җирләрдә сирәк очрый торган үлән, җәнлек, кошларга тап булганнар комитетка мөрәҗәгать итә икән. Кайбер районнар үзләрендә тыюлык ясауны да сораган. Лениногорск районында «Покш Пандо» табигать һәйкәле куелган.

Брифингта Лениногорск районының башкарма комитет җитәкчесе Зөлфия Михайлова да катнашты. Ул үз районнарындагы табигать байлыклары турында сөйләде. Районда байбакларның кимеп баруын җиткерде.

2022 елда Балтач районында ылыслы агачларны саклап калу максатыннан «Чепья урманы» дип аталган табигать һәйкәле төзелгән.

– Татарстанда яшәүче һәр кеше хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын күзәтүдә катнаша ала. Үзләренә очраган сирәк төрләр турында комитетка җиткерергә кирәк. Хәбәрне электрон рәвештә тапшырырга мөмкин. 2018 елда белгечләр 1458 шундый хәбәр алса, 2022 елда 3394 кеше мөрәҗәгать итте. Димәк, халык тирә-якка битараф түгел, – ди ул.

Еш кына кешеләр, хайваннар яшәгән тирәлеккә кереп, йорт сала, нидер төзи, сәүдә итә башлый. Әнә шуннан соң биредә яшәүче кошлар каядыр очып китә, хайваннар кими. КФУ профессоры Татьяна Рогова да шул фикердә.

– Табигать үз көенә, үзенчә яшәргә тиеш. Аңа да тынычлык кирәк. Әнә шуңа күрә, ниндидер эш башлаганчы, киңәшмичә ярамый. Монда бик мөһим карар кабул итәргә кирәк булачак. Төзи башлаганчы ук, экологияне кайгырту мөһим, – ди ул.

Федор Батков, хайваннарның күбесе машина астында калып һәлак була, ди.

– Авария куркынычы булган җирләргә махсус билгеләр дә куябыз. Әмма машина йөртүчеләр моңа бик игътибар итми. Хайваннар юлның теләсә кайсы ягыннан килеп чыгарга мөмкин. М12 юлында хайваннар өчен күтәртмәле юл булачак. Әлегә 11 җир асты юлы бар. Бер генә үтенеч – йөртүчеләр сак булсын иде, – ди рәис.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Бала зары

Россиядә яшүсмерләр тарафыннан кылынган авыр җинаятьләр саны 22,5 процентка арткан. Бу – соңгы биш елдагы иң зур күрсәткеч. Аның каравы җинаятьләрнең гомуми саны кимегән. Россиянең балалар омбудсмены Мария Львова-Белова күптән түгел 2022 ел өчен хисап тотты.

Хокук бозулар

«Балигъ булмаганнар катнашында кылынган авыр җинаятьләр саны 22,5 процентка арткан. Башкача әйткәндә, 2256 очрак дигән сүз бу. 2021 елда 1841 очрак иде. Бу – соңгы биш елда теркәлгән иң зур күрсәткеч», – диелә Мария Львова-Белова хисабында.

Шул ук вакытта балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләрнең гомуми саны 4,4 процентка кимегән. 2021 елда бу сан 31,9 мең булса, узган елгы күрсәткеч – 30,5 мең. Җинаять кылуда 26,3 мең яшүсмер катнашкан. 2021 елда кырын эштә 29,1 бала тотылган.

Шомга салган саннар да бар. Омбудсмен әйтүенчә, үсмерләр арасында көчләү (151 очрак), мошенниклык (988 очрак) кебек җинаятьләр саны арта.

Кимегән

Уңай үзгәрешләр дә юк түгел. Әйтик, сабыйлар үлеме 9,4 процентка кимегән. Балигълык яшенә җитмәгәннәрнең үз-үзенә кул салу очраклары да 9,8 процентка азайган. Тәрбиягә алынган балаларга карата җинаять кылган өчен җинаять җаваплылыгына тартылган ата-аналар, опекуннар саны 78,6 процентка кимегән.

Нәрсәдән зарланалар?

Федераль омбудсменга килгән мөрәҗәгатьләр саны узган ел 26,8 процентка арткан. Чагыштыру өчен: 2021 елда 9,5 мең зар кабул иткәннәр.

Саны үзгәреп торса да, мөрәҗәгать итү сәбәпләре шул ук кала. Әйтик, ата-аналарны балаларын бакчага, мәктәпкә урнаштыруда килеп туган сораулар борчый. Моннан тыш бакча һәм мәктәпләрне төзү, төзекләндерү кебек мәсьәләләргә карата да битараф түгел алар. Моннан тыш пособие алу, сабыйлар сәламәтлегенә бәйле сораулар да юк түгел. Чорына күрә мобилизациягә кагылышлы зарлар да күп булган.

Ольга СЕРЕБРОВСКАЯ, клиник психолог:
«Яшүсмерләр белән җинаять кылынганчы эшләргә кирәк. Психологлар моңа китергән сәбәпләр белән эшли ала. Әлбәттә, бу эштә ата-аналар да катнашырга тиеш. Яшүсмерне шунда ук учетка бастырырга кирәкми. Бу – җәза чарасы гына. Балага ярдәм итәргә һәм аның кырын тәртибенең сәбәпләренә йогынты ясарга кирәк».

Уңыш-2023

СЫНАТМАСКА!

Ниһаять, бу атнада барлык хуҗалыклар да уракка төште. Яңгыр мулдан явып, моңа кадәр керә алмыйча торган басуларда да комбайн гөрелтесенең тынып торганы юк. 1 август мәгълүматлары буенча, республикада 292 мең гектардан артык мәйданда 845 мең тоннадан артык ашлык җыеп алынган. Уртача уңыш – гектарыннан 28,9 центнер. Кайсы район нинди уңыш белән сөендерә соң? Без шуны белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Быел Арча районына яңгырлар чагыштырмача мулрак эләкте. Һәрхәлдә, июнь аенда республикадагы корылык турында язма әзерләгәндә, иң күп явым-төшем аларга туры килгән иде.

– Быел беренче уракка 1,5–2 атна элек төшкән идек. Шуннан соң яңгырлар яву сәбәпле, бераз тоткарланырга туры килде. Шуңа күрә бөтен хуҗалыклар да бу атнаның дүшәмбесендә генә керештеләр, – диде районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ленар Абдуллин. – Балтач районына якын булган «Ватан» агрофирмасы кырларында соңгы атналарда явым-төшем күп булды. Шунлыктан алар керә алмыйча торган иде. Язгы кыр эшләрен башкарганда һәрвакыт зуррак уңышка өмет итәбез, әлбәттә. Барлык эшләрне җиренә җиткереп башкарабыз. Тик уңыш без көткәнчә түгел инде. Телибезме-юкмы, табигать шартлары үз эзен калдыра. Әйтик, Мари Эл белән чиктәш хуҗалыкларда июль уртасына кадәр бер тамчы яңгыр яумады. Аларда уңыш та шуның кадәр генә. Районда бу вакытка 176 мм явым-төшем булырга тиеш иде, тик аның яртысын да җыеп бетереп булмады.

Идарә башлыгы сүзләренчә, язгы культуралар бераз сынатса да, көзге культураларга өмет зурдан.

– Яңгырлар явып узган басуларда уңыш начар түгел, – ди ул. – Әлегә гектарыннан 28,5 центнер уңыш алабыз. Комбайннар борчак, көзге бодай һәм арпа басуларында эшли. Язгы бодайга әллә ни өмет баглап булмый, чөнки сирәк тишелде. Арпа да шулай ук. Соңгы яңгырлар вакытында боз да төшкәләде, ул да бераз зыян салды. Терлек азыгын җитәрлек әзерли алдык.

Аграрийлар өчен уңышны җыеп алу гына түгел, аны отышлы бәядән сату да мөһим. Тик әлегә анысы куандырмый.

– Гомумән алганда, кәеф начар түгел, – ди бу уңайдан Ленар Абдуллин. – Тик аны кырган иң зур нәрсә – җитештергән продукциягә бәя булмау. Арыш бүген 6–6,5 сум тора. Сөтнең бәясе булмаганлыктан, төзелеш планлаштырган хуҗалыкларның эшләре торып тора. Аңа карамастан, кыр батырлары үзләренә йөкләнгән эшне тиешле дәрәҗәдә башкарып чыгарга тырыша.

Баулы – явым-төшем иң аз эләккән һәм май суыклары шактый мәйданнарына зыян салган районнарның берсе. Монда кыраулар төшеп, 2000 гектардан артык мәйданнардагы культуралар һәлак булды. Аларны кабат чәчәргә туры килде.

– Уракка узган җомгада төшкән идек. Әлегә көзге культураларны суктырабыз, – диде авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Альберт Талипов. – Безнең районда чәчүлек басуларына корылык кына түгел, салкыннар да зур зыян салган иде. Кәефләребез бик төште. Шөкер, июль башыннан бирле яуган яңгырлар кабат чәчкән басуларга җан өрде, зыян килгәннәренә дә файдасы зур булды. Андый культураларның уңдырышлылыгы азрак, әлбәттә. Гектарыннан 16–20 центнер гына чыга. Ә язгы культураларның уңышы 20 центнердан күбрәк булыр дип өметләнәбез. Шуңа күрә кәефләребез начар түгел. Терлек азыгы җитәрлек. Июль яңгырларының файдасы зур булды.

Кыраулар зур зыян салган тагын бер район – Минзәлә аграрийларының да хәлен белештек.

– Былтыргы кебек рекордлы күрсәткечләр юк, әлбәттә. Шуның яртысы гына. Район буенча уртача 28 центнер уңыш чыга. Булганының бөртеген дә әрәм итмичә җыеп алырга кирәк, – диде идарә башлыгы Илфар Халиков. – Кырауның күңелсез нәтиҗәсе булды инде ул. Көзге культуралар матур гына кышлаган иде югыйсә. Хәзер ява торган яңгырлар бер ай алдан булса, тагын да яхшырак буласы иде. Ләкин безнең очракта аның бервакытта да артыгы юк. Явым-төшем техник культураларга, язгы арпа, бодай, арышларга аеруча кирәк иде. Анысына сөенәбез генә.

Кама Тамагы районында да эшләр тулы куәтенә бара. Хәзерге вакытта барлык чәчүлек мәйданнарының 17 процентыннан 26 мең тонна икмәк суктырганнар. Идарә башлыгы Илфат Вәлиев әйтүенчә, чыгышы уртача 39–40 центнерны тәшкил итә.

– Бездә дә корылык булды, ләкин технология белән эшләү файда бирде. Әлегә без чыккан икмәктән канәгать. Борчактан кала, башка язгы культураларга тотынмадык әле. Бездә июльдә дә яңгырлар әллә ни күп булмады, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Республикада урып-җыю барышы

Район	Суктырылган мәйдан (гектар)	Җыелган ашлык (тонна)	Уңдырышлылык (гектарыннан центнер)
Аксубай	16213	40132	24,8
Буа	5086	47668	31,6
Биектау	2190	6911	31,6
Кайбыч	6530	25092	38,4
Мөслим	7477	16080	21,5
Тәтеш	11585	52113	45,0
Ютазы	2350	4058	17,3
Чистай	5989	18602	31,1

*Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының оператив мәгълүматлары буенча

УКУЧЫ СҮЗЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

АЛМАЛАРНЫ КЕМГӘ САКЛАДЫМ?

Күзләр җиткәнлеген тоймый калдым,
Бәргәләнеп җилләр иссә дә.
Җил капкадан кемне көтәм соң мин,
Килми калганлыгын белсәм дә?

Күзләр җиткәнлеген сизми калдым –
Агачында әле алмалар.
Алмаларны кемгә сакладым соң,
Янган күңелемне алдалап?

Күзләр үткәнлеген күрми калдым,
Кыйгач яңгырлары яуганда.
Керфекләрдә яшьләр икәнлеген
Тоймаганмын, тамчы тамганда.

...Инде килсә, кышлар җиткән икән,
Җил капканы күмгән ак карлар.
Шәмнәр булып алмагачта яна
Кышка калган сары алмалар.

Нәфисә ХӘБИБДИЯРОВА

ИҢ ТАТЛЫСЫ – ХӘТЕР САНДЫГЫНДА

Безнең гаиләдә җәй айлары әти-әниебезнең яшьлек туйларын хәтерләтеп тора. Әниебез Фәридә белән әтиебез Ринат Әкбәровлар 1963 елда кавышканнар. Быел бриллиант туйларын билгеләп үттеләр.

60 ел бергә гомер итү бәхете бик күпләргә тәтеми. Ә шул елларны сынатмыйча үтү – үзе бер мәртәбә. Еллар узган саен, без аларга карап сокланабыз. Әти-әниебез Ходай насыйп иткән гомерләрен мәгънәле һәм матур итеп яши белә. Һәр эшне яратып, җиренә җиткереп башкаралар, аларны хөрмәт итмәгән кеше юк.

Кече Кариледә башлангыч мәктәпне тәмамлагач, башка яшьтәшләре кебек, икесе дә Олы Кариле авылына йөреп белем алалар. Ничәмә километр юлны җәяү үтәрлек көч тә, дәрт тә булган бит! Укудан соң мәктәптә узган чараларда катнашалар. Авыр булса да, ул еллар, иң татлысы булып, хәтер сандыгында саклана, ди алар.

Диңгез флотында өч ел хезмәт итеп, рухын ныгытып, тәҗрибә туплап, туган якларын сагынып кайта әти. Бәхетен читтән эзләми: киләчәген туган ягына бәйли. Ул чакта «матур Ринат» дип исем алган кара бөдрә чәчле, төз гәүдәле, йөрәкләрне өздереп гармунда уйнаган егеткә бик күп кызларның хисләре бөреләнсә дә, ул шулар арасыннан сабыр холыклы, акыллы, эшкә уңган-булган, егет солдат хезмәтендә булганда буй җиткергән әниебез Фәридәне сайлап, иптәш егете Зөфәрнең елкылдап торган «Волга» машинасында килеп, Сабантуй атнасында кызның кулын сорап китә. Ул чактагы гадәт буенча кызны урлап алып кайтмый, авылда беренче булып, хөрмәт белән килеп, хисләрен аңлата, әбиебез Нәгыймә һәм бабабыз Миңнеҗанга ниятен җиткерә.

Әти-әниебезнең яшьлек тормышы тырыш халкы белән дан тоткан Кама Тамагы районында узды. Авыл тормышы җиңел булмагандыр, ләкин алар беркайчан да зарлануны белмәде. Яз җитүгә, бакча эшләренә тотындылар. Җәй буе бакчалар яшелчә, җиләк-җимештән гөрләп торды. Чебиләр, казүрдәкләр, мал-туар йөгерешеп йөрде. Хезмәт алар өчен һәрвакыт зур энергия чыганагы булды. Хөкүмәт эшеннән соң җәмгыятькә файдалы хезмәткә дә вакыт таба иде алар. «Эшләп кеше үлми. Эштән курыкмагыз! Тырыш булыгыз!» – дип өнди хәзер дә әниебез.

Әти белән әни һөнәрнең дә аяк өсте йөреп, зур хезмәт куеп эшли торганын сайлаганнар. Әтиебез гомеренең 43 елын Олы Кариле урта мәктәбендә балаларга белем бирүгә багышлады. Эшен чын күңелдән яратып, бөтен белемен, энергиясен, көчен кызганмыйча башкарды. Тирән белемле, гел яңалыкка омтылучы укытучы абыйларын балалар да үз итте. Ул чакта трактор йөртү серләрен мәктәптә үк үзләштереп, таныклык алып чыккан шәкертләре бүген дә «тимер ат»та басу-кыр киңлекләрен иңлиләр. Араларында атказанган механизатор дигән мактаулы исемгә лаек булучылар да, инженер дәрәҗәсенә ирешкәннәр дә бар. Димәк, тырышлык бушка китмәгән.

Коллективта һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер һәм югары әхлак сыйфатларына ия булган шәхес булды ул. Олыларны – олы, кечеләрне кече итә белде. Өлкән яшьтәге кешеләргә игътибарлы һәм ихтирамлы булды. Әле аның дәү әти Габделхәйдән күчкән, ни тотса, шуны гөл иткән алтын куллары, балта остасы, электрик, ватык-җимерек көнкүреш техникасына җан кертә белү осталыгы – үзе бер могҗиза кебек. Бүген әтинең эшен кызы Гөлкәй дәвам итә, ул да Олы Кариле урта мәктәбендә 33 елдан артык балаларга белем бирә.

Әниебез берьюлы өч-дүрт эштә эшләде. Мәктәптә техник хезмәткәр һәм шул ук вакытта мәктәп ашханәсендә пешекче, хат ташучы иде ул. Олы Кариле авылында хат ташучы булып эшләгәндә, һәр йортта көтеп алынган кунак булды. Кышкы буранлы көннәрдә дә, көзнең салкын яңгырларында да матбугатны вакытында таратты. Ә бит ул чакта хәтта почта тартмасына да сыймаслык булып һәр өй дистәләгән газета-журнал алдыра, көн саен диярлек туган-тумача арасында хатлар йөри, бәйрәм көннәрендә котлау открыткалары килә иде. Күрше авыллардан килеп укучылар, атна буе тулай торакта яшәп, ял көннәрендә генә өйләренә кайтып йөрүчеләр әниебез пешергән тәмле ашларны хәзер дә рәхмәт хисләре белән искә ала. Намуслы хезмәте өчен ул «Хезмәт ветераны» исеменә лаек булды, бик күп мактау кәгазьләре, рәхмәт хатлары бар.

60 ел буена шатлыклары да, кайгылары да уртак булган әти белән әниебезнең. Тату гаиләнең мәхәббәт җимешләре булып, биш бала дөньяга килгән. Бишебезгә дә – 4 кызлары Гүзәлия, Розалия, Гөлкәй, Гөлнурга, көтеп алынган төпчек уллары Маратка яхшы тәрбия һәм югары белем биреп, зур тормышка аяк бастырдылар. Бишебез дә үз тормышыбызны корып, инде хәзер үзебез балалар тәрбиялибез, укытабыз, оныклар сөябез.

Гомерләре буена изге юлдан барган, тормыш авырлыкларыннан сынмаган-сыгылмаган әти-әниебезгә без чиксез рәхмәтле. Алар безнең өчен – зур бер өлге, ун онықлары һәм ун оныкчыклары өчен үрнәк булып тора. Кадерлеләребезнең хәзерге көндә исән-сау булуларына, изге догаларыннан ташламыйча, безгә терәк булып торуларына без бик шат. Барыбыз да әти-әнинең алдагы көннәре саулык-сәламәтлек белән, тигезлектә үтсен, балалар-оныклар бәхетен күрергә язсын дигән теләктә калабыз. Әле озак еллар әти-әнинең изге догаларын тыңлап, йөрәк җылысын һәм шифалы сулышларын тоеп яшәргә насыйп булса иде!

Гөлнур ӘКБӘРОВА

Гармунчы Васил

Студент чаклар һәрберебез күңеленә күңелле хатирәләр белән кереп калган. Һәр минутның кадерен белеп, файдалы үткәрергә тырыштык. Университет китапханәсе ябылганчы, китаплар, журнал-газеталар укып утыра идек. Уку мавыктыргыч һәм кызыклы иде.

Сентябрьдә колхозларга уңыш җыярга, бәрәңге алышырга булыша идек. 1981 елның сентябрендә безне, журналистика бүлеге студентларын, Саба районындагы «Марс» колхозына җибәрделәр. Уртак хезмәт безне аралашырга, ярдәмләшеп яшәргә өйрәтте. Коллектив хезмәт дуслыкны тагын да ныгытты. Иң мөһиме – җитәкчелек, ак атта йөрүче яшьтәшебез, «Марс» колхозы бригадиры Гаяз Гәрәев безнең эштән һәрвакыт канәгать. «Үрнәк булырлык эшләдегез!» – дия иде.

Фотодагы бердәнбер егет – ике группа: 3 нче һәм 4 нче курс журналистика бүлеге студентлары өчен җаваплы комсомол, гармунчы Васил ул. Хәзер КФУның милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире, филология фәннәре докторы, профессор Васил Заһит улы Гарифуллин.

Равилә МӨБАРӘКШИНА

Туксан яшенә – бүләк

Әгерҗе районы Кичкетаң авылында яшәүче Фәния Закирова, 90 яшьлек юбилеен каршы алгач, үзенә бүләк ясады: зур теплица сатып алды. Алай гына да түгел, ир-атлар аны урнаштырып киткәч, көн буе тачка белән тирес һәм туфрак ташып, утыртырга үсентеләр дә әзерләп куйды.

Гүзәл Иж буенда урнашкан Балтач авылы кызы ул. Җиде балалы зур гаиләдә икенче булып дөньяга килә. Мәктәпкә дә ике елга якын гына йөреп кала. 11 яшеннән колхоз эшенә керешә. Болай да авыр тормышлары, сугыштан кайткан әтиләре 46 яшендә дөнья куйгач, тагын да кыенлаша. Көннәре колхоз басуында кышын кар тотып, җәен утау эшләре белән, көзен ындыр табагында ашлык киптереп үтә. Яшүсмергә урман кисү эшләре дә яхшы таныш. Районыбызның Мадьяр, Рус Шаршадысы, Татар Чилчәсе урманнары гына түгел, ерак Куйбышев, Әлмәт, Бөгелмә тирәсендәгеләргә дә җибәрәләр аларны. Актаныш якларыннан килеп, Чәчкә авылында төпләнгән Зәки атлы егеткә кияүгә чыккач, анда таналар карый. Гаиләне тулыландырып, уллары Флүр дөньяга килә. Тик парлы тормышлары гына озын гомерле булмый. Фәния Чәчкәдә өч ел яшәгәч, кире туган йортына кайтып, әнисенә үзеннән кече эне-сеңелләрен аякка бастыруда булыша, улы Флүрне тәрбияли. Фермага эшкә урнашып, 41 ел сыер сава. Лаеклы ялга чыккач та яраткан малкайларыннан аерылмыйча, тырышып хезмәт куя.

– Балтач авылы күчерү зонасына эләккәч, шактый мәшәкатьләр күрергә туры килде. Әле ярый колхоз яшәр өчен йорт бирде. Кичкетаңга фермадагы малкайларым белән бергә күчендек. Эшемне тырышып, җиренә җиткереп башкарырга тырыштым. Хезмәтемә күрә хөрмәтне дә күп тойдым. Алдынгылар слетына кайларга гына йөртмәделәр?! Авыл һәм район Советларына депутат итеп тә сайладылар. Суыткыч, телевизор, кер юу машинасы, радио, келәм һәм башка бик күп әйберләр бүләк иттеләр. Ә иң кадерлесе – 1976 елда бирелгән «Мактау билгесе» ордены, – дип горурланып сөйли хезмәт ветераны.

Бүген рәхәтләргә һәм рәхмәтләргә төренеп яши хөрмәтле Акъәби. Бер үк урамда гомер кичерүче сеңлесе Гөлсөяр, Буадагы сеңлесе Флүрә бик рәхмәтле бертуганнарына. «Үскәндә мәрхәмәтле, кайгыртучан апабыз булса, хәзер әниебез урынына калган кадерле кешебез ул», – диләр.

– Мин әниемне хәтерләмим, бик яшьли вафат булган. Әбием, оныгым ятимлекне сизмәсен дип, яраткан эшеннән китеп, ике яшемнән үстерде мине. Башта көллияттә, аннан институтта укыдым. Хәзер дә аның ярдәмен тоеп яшибез. Киң күңелле, алтын йөрәкле ул. Мин аның алдында бурычлы, – ди оныгы Рәзинә. – Нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә, аз булыр кадерле кешебезгә.

Авылдашларының да зур хөрмәтен тоеп яши Фәния апа. Эштән кайтып, кичләр буе йон оекбашлар бәйләп сатуы, 89 яшенә кадәр абзарында үгез асравы, бакча тутырып яшелчә, бәрәңге үстерүе, чисталык-пөхтәлек яратуы турында сокланып сөйли алар. Әнә улы Флүр һәм килене Римма Чаллыдан кайтып, баздан чыгарган 26 капчык (!) бәрәңгене дә ике көн эчендә чистартып куйган ул.

– Юбилеема кайтуларына эш көтеп тормасын аларны! – дип аңлатты ул бу гамәлен.

Әле һаман да башкаларга ярдәм итеп, аларны кайгыртып, 90 яшендә дә актив тормыш белән яшәүче, җәйләрен көн буе бакчада хезмәт куючы бу әбекәйгә, чыннан да, сокланмыйча мөмкин түгел.

Асия КОРБАНГАЛИЕВА

Менә кайда ул театр!

Сәхнә әсәре турында аның үзен театрда карагач сөйләшсәк, дөресрәк булыр иде. Әмма пьеса әдәби журналда басылып чыккач, фикерләшеп алсак та ярар кебек, минемчә. Сүзем – Илгиз Зәйниевнең «Чия тавы» дип аталган ике пәрдәле драма әсәре турында.

Алдан ук әйтим: бирелеп укыдым мин пьесаны, яхшы язылган проза әсәре кебек укылышлы ул. Илдар атлы абзый газиз баласы фаҗигасеннән тәмам гаҗиз булган. Әсәрнең төене ничек чишелер икән, дип кызыксынып укыйсың. Пьесада кечкенә генә деталь дә үз урынында. Мәсәлән, Илдарның тормыш иптәше Алсу, улының өйгә кайтуын белер өчен, кичен аның урынына ятып йоклый икән. Яраткан улын көтә ул. Драманың төене исә иң соңгы күренештә чишелә. Бар хикмәт Регина һәм Илшат арасындагы мөгамәләдә икән. Регина – Илдар белән Алсуның кызы, Илшат – главаның кияве, гаиләле ир-ат. Без алар арасындагы катлаулы хәлләрне кеше сүзеннән генә аңлап беләбез. Илдар белән Алсуның улы Марсель сөйләп бирә сеңлесенең фаҗигасен: «... Сез бит бернәрсә белмисез, бернәрсә... Алай җиңел генә булса икән ул. Алар ике ел очрашып йөрделәр... Илшат белән Регина... Гаиләсе бар шул... Синең тәти кызың, яраткач, нишләсен... Регина аборт ясатты. Илшат ясаттырды. Үзе дә сездән куркып ризалашты. Регина... Балакаем. Әллә мин аны яратмый идем, дисеңме? Без бит гел бергә идек... Әллә мин төннәрен еламый, дисеңме?.. Ул бит ярты ел буена саташып йөрде. Ул бит... Төннәр буена бала елаганын ишетәм дия иде...»

Менә кайда ул фаҗига, театр!

Әмма без аның белән хозурланудан мәхрүм. Регина белән Илшат арасында булган буталчык хәлләрне без кеше авызыннан ишетеп кенә беләбез. Үзләре хәтта персонажлар исемлегендә дә юк. Төп вакыйга тамашачы күз алдында бармый. Их, сәхнә түрендә менә шул персонажлар драмасы уйналса иде ул!

Ильяс САЛИХҖАН

ТУГАННАРЫ КҮП КЕШЕ БӘХЕТЛЕ

Быел Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнендә олы бер нәселнең җиде буыны, 500гә якын дәвамчысы Түбән Кама районының Түбән Чаллы авылында туганнар җыенына җыелды. Һәр нәсел тармагы үзен танытырдай төскә бизәлгән иде. Җәйге төсләрне тагын да баетып торган күренеш булды бу.

Җыенның «идея атасы» Зәйнулла токымының бишенче буын вәкиле, шушы авыл егете Райхан Гайнуллин булды. Башкалар аның фикерен дәррәү күтәреп алдылар. Ир-егетләр җыен буласы мәйданны әзерләүгә, аш-су өлгертеп, туганнарны зурлап сыйлау, кунак итүгә, уеннар үткәрүгә алындылар. Зур-зур казаннарда, бөтен тирә-якка тәмле исләр таратып, пылау пеште, шулпа өлгерде. Бихисап самавырлар, пуф-пуф килеп, җырлап утырды. Һәр хуҗабикә үзе оста итеп пешерә торган ризыгын әзерләп килде. Бер өстәлдән икенчесенә күчеп, туганнарны сыйлап йөрделәр. Туганнарны барлап, берләштереп торучы тагын бер күркәм ир солтаны Зәйнулланың өлкән улы Гайнулла оныгы Зәйнәгетдин Әхмәтзәки булды.

– Мондый очрашуны күптән оештырасы килеп йөри иде, – диде ул. – Иң элек 77 кешедән торган уртак төркем һәм оештыру комитеты тупланды. Биш юнәлешкә җаваплы кешеләр билгеләнде. Болар – тарихи күргәзмә, бүгенге кул эшләре, концерт программасы, уеннар һәм сый-хөрмәт әзерләү. Киләчәктә бу җыенны һәр биш ел саен оештырып, традициягә әйләндерергә уйлап торабыз.

Нәсел агачын белү, эзләү – барыбызның да изге бурычы. Шуңа күрә бик күпләр шәҗәрә агачы төзеп кайтканнар иде. Нәселебез зур, киң тармаклы. Арабызда төрле эшне дә җиңеп чыгардай кешеләр күп, шөкер.

Бәйрәм сценариен төзүчеләр, сәхнәдәге концерт программасын әзерләүчеләр, алып баручылар күп төрле җыр конкурсы лауреатлары, җырга-моңга, шигърияткә гашыйк өч бертуган кыз – Фирдәүсә Бикмәтова, Флүрә Гыйниятова һәм Флүзә Йосыпова булды.

Арабызда зур уңышларга ирешеп, безнең ыруны гына түгел, милләтебезне, халкыбызны данларлык туганнар бик күп. Аларны санап бетерерлек түгел. Шуларның берсе – Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы, Кама Тамагының муниципаль берлеге Советы депутаты Рифнур Зәйнуллин. Түбән Кама районы Кызыл Чапчак авылында гаилә фермасын җитәкләүче механизатор Марат Абзалов белән дә горурланабыз. Атасы эзеннән киткән улы Мурат 2016 елда Казанда WorldSkills бәйгесендә катнашып, 1 нче урынны яулап кайтты. Кырык дүрт ел буе балаларга математика укыткан хөрмәтле укытучыбыз Халидә

Бикчәнтәева Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Халык мәгарифе отличникгы» билгесе белән бүләкләнгән. Бер туганыбыз Ильяс Газыймов гомерен сәнгатькә багышлаган. Рәсемнәрендә табигать күренешләрен сурәтләүгә өстенлек бирә. Җыенда ул иҗат иткән милли бизәкле сөлгеләр дә үз хуҗаларын тапты.

Зәйнулла нәселенең ир-атлары гомер-гомергә балта осталары булган, ә хатын-кызлары тегү-чигү һәм башка кул эшләре белән тирә-юньдә дан тотканнар. Үзем туып-үскән төп нигездә әнием Нурдидәнең олы абыйсы Әхмәтзәки абый таҗлап, челтәрләп ясаган тәрәзә кәрнизләре һаман да аның кул җылысын саклый кебек!

Нәселебезнең биш буын хатын-кызлары җан җылысын салып бизәкләгән кул эшләренең серен, буыннан-буынга күз карасыдай саклап, кызларына тапшырып килгән. Туганыбыз Гөлфия Хәлиуллина, әни-әбиләрнең кул эшләрен, бабайлар эшләгән бала бишеге, урындыкларын куеп, авыл өен ясаган иде. Ул үзе дә – тегүче. Мөселман киемнәре тегә. Халыкара һәм Россия күләмендә үткәрелгән бәйгеләрдә катнаша.

– Хәзер балаларым белән кияүгә китүче кызларга бирнә әйберләре әзерлибез, – ди ул.

Җыенда иң кечкенә һәм иң өлкән кеше дә билгеләнде. Иң кечесе Зәй районының Бигеш авылыннан килгән бер ай ярымлык Латифа Ханнанова булса, иң өлкән хатын-кыз да шушы тармактан – гомере буе Түбән Кама районының Шәңгәлче авылында яшәп, пешекче булып эшләгән 85 яшьлек Шәмсесорур апа иде.

95 яшьлек аксакалыбыз Әбүбакир бабай Шәйдуллин 4 ел буе Кытайда авиация полкында техник булып хезмәт иткән. Демобилизациядән соң Казан авиация заводында эшләгән. Почет билгесе ордены белән бүләкләнгән.

– Туганнары күп кеше бәхетле ул! Үз-үзеңә бикләнеп яшәргә ярамый. Балаларым, онык-оныкчыкларымның менә шулай бер-берсен белергә теләп очрашуларына бик шатмын. Исән чакта күреп калганыма бик сөенәм, – ди ул.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

Язучы сүзе

Шәһәр

Мин кайттым һәм аны танымадым. Ул үзгәргән, матурланган иде.

Шәһәр чынлап та матур иде. Ходай тарафыннан онытылган дөньяның нәкъ уртасында калкып чыккан бу шәһәр читтән караганда да иң яхшы сәнгать әсәре кебек күренә, аның нәзакәтле төгәллек белән төзелгән урамнары да, йортлары да, ара-тирә калкып чыккан манаралары да әллә нинди бизәкләр хасил итә, кояш нурында төрле төсләргә кереп балкый иде. Гади шәһәр болай була алмый. Хәтта бөек шәһәрләр дә бу дәрәҗәгә җитәлми. Бары тик мәшһүр осталар бизәкләгән асылташлар гына шул дәрәҗәдә җемелди аладыр. Ләкин бу андый камиллеккә җиткән йөзек кашы түгел, ә олы бер шәһәр, кешеләр яши торган урын иде.

Урам буйлап тезелгән машиналарына кадәр ниндидер бер төгәллек белән агыла, юлларга сыймаслык дәрәҗәдә күп булсалар да, алар күзгә чалынмый торган катгый тәртип белән хәрәкәт итәләр: тыгылмыйлар да, тоткарланмыйлар да, хәтта тизлекләрен дә киметмиләр. Читтән караган кешедә дә бу чиксез соклану уята, гадәти чынбарлык булудан бигрәк, даһи фокусчының чыгышы сыман тоела иде.

Машиналар гына түгел, җәяүлеләр үзләре дә шулай. Алар урамнарның, машиналарның, йортларның, йолдызларга ашкан манараларның бөтен матурлыгын, бөтен сыйфатын үзләренә туплаганнар кебек. Хәер, юк… алай түгелдер, кешеләрнең әнә шул чиксез камиллеккә ирешкән матурлыгы алар яшәгән дөньяның үзендә дә чагыла торгандыр.

Кешеләр матур иде.

Башта аларның үз-үзен тотышы, атлап йөрешләре, үзенчәлекле биюгә тиң хәрәкәтләре әсир итте. Юк, алар сикергәләмиләр дә, төрле әгъзаларын боргалап та маташмыйлар… Алар ниндидер бер тәңгәллек белән, искиткеч төгәллек белән әсир итә. Шуңа күрә гади генә табигый хәрәкәтләре дә сoклангыч гүзәллеккә әверелә. Атлап йөрү сәнгате. Кул селтәү, борылып карау сәнгате…

Бу чынлап та сәнгать һәм камиллек иде. Урам буйлап чалыш-чолыш атлаган ирләр дә, әниләренә ияреп көйсезләнгән балалар да күренми. Үзара талашып я әреплəшеп барган гашыйк парлар да юк. Телефонына капланып каядыр чапкан затларны да күрә алмассың. Беркем беркая ашыкмый, барысының да тормышлары җиткән, алар үз дәрәҗәләрен һәм кадерләрен белеп, һәр мизгелнең ләззәтен тоеп хәрәкәт итәләр, һәр хәрәкәтләре тормышка матурлык өсти. Без кайчандыр сәнгать тудырырга тырыша торган идек. Рәсемнәрдә, сүзләрдә, хәрәкәтләрдә. Без, сәнгать эзләп, китаплар укый, концертлар карый, театрларга йөри идек. Ә монда аларның барысы да артык. Монда кешеләр тормышның үзен сәнгатькә әйләндергән, болар яшәүне зур сәнгать иткән.

Мин аз гына читкәрәк китеп, бер эскәмиягә барып утырдым. Ят булып күренәмдер, мондый затлар арасында яши алу өчен дә әллә нинди зур талант кирәктер сыман тоелды.

Күзләремне йомып, сүзләренә колак салдым. Бернинди кычкырышу, бернинди бәхәсләшү юк. Барысы да театр артистлары шикелле матур тавыш белән аралаша, тулы җөмләләр белән сөйләшә. Елмаеп әйтелгән сүзләрен күзләреңне йомган килеш тә чамалап була. Телнең бөтен нечкәлекләрен беләләр, сүз байлыклары да сокланып туймаслык. Аларны тыңлау – үзе бер ләззәт, колакларыңны иркәли, күңелгә сихәт бирә. Шул тавышлар арасында күзләреңне йомып утыру үзе генә дә җәннәт шикелле тоела.

Тик бераздан мин күзләремне ачтым. Ачмаска кирәк булган. Ләкин кешеләрнең бу кадәр камиллеге шулкадәр сәер булып күренде дә аның сәбәпләрен эзләргә мәҗбүр итте. Кешеләр бу дәрәҗәдә үк камил була алмыйдыр, берәр кимчелекләре бардыр, аларны мин генә күрмимдер сыман булды. Һәм мин күзләремне ачтым. Ачмаска кирәк булган. Бәхетеңне озаккарак сузарга теләсәң, күзләреңне йомып яшәргә кирәк.

Башта мин аларның сүзләренә игътибар иттем. Күзләремне ачканчы ук әле. Болар тулы җөмләләр белән сәнгатьле итеп гел дөрес сүзләр генә сөйлиләр иде. Матурлык турында, җиңүләр, уңышлар турында сөйләшәләр. Тормышны мактыйлар, җитәкчеләргә рәхмәт яудыралар. Болар үзләрен уратып алган бөтен нәрсәдән дә канәгать, бөтен нәрсәгә дә рәхмәтле иделәр. Кеше табигате өчен бу бераз сәер тоелса да, мин аларны аңлый ала идем. Шушы тиклем камил тормышта яшәгән затлар бернидән дә зарлана алмый торгандыр, алар нәкъ менә шулай булырга тиешләрдер.

Аннан соң киемнәренә игътибар иттем. Һәркайсының өстендә иң яхшы тукымалардан шундый матур итеп тегелгән затлы кием. Һәркайсыныкы үзенә килешеп, гәүдәсенең зифалыгын ассызыклап тора. Һәм ул киемнәр әле генә энәдән төшкән шикелле, тамчы да таушалмаган иде. Бу миңа сәер тоелды. Болар беркайда да эшләми, берничек тә пычранмый микәнни дип уйладым.

Кызыксынуым көчле булып, бик күп нәрсәләрне сорашырга теләсәм дә, яннарына килеп эндәшергә кыймый йөрдем. Мин алар арасында беркадәр чит кеше кебек идем. Һәркайсының үз юлдашы, үз әңгәмәдәше бар һәм башкалар белән беркем дә кызыксынмый, һәр төркем үз юлы белән бара, һәрберсе үз дөньясында яши сыман тоелды. Хәтта ялгыз атлаганнары да үз халәтенең ләззәтен тоеп атлый, нәрсәдер эзләп, карашлары белән капшанып йөргән бер кеше дә юк.

Мин үземне урманда, агачлар арасында сыман хис иттем дә кошлар тавышын ишетергә теләп, колакларымны торгыздым. Тыңларга җай табалсаң, шәһәр җире дә кошлардан мәхрүм түгел ул. Тик мин берни дә ишетмәдем… Һәм күңелне шом басты…

Кешеләрнең сәнгатьчә матур хәрәкәте бер мизгелгә чынлап та үзенчәлекле бию булып күренде. Меңәр тапкыр кабатланып, камиллек дәрәҗәсенә җиткерелгән хәрәкәтләр. Сүзләре дә театр актерларыныкы кебек тоелды. Кемнәрдер тарафыннан язылган матур җөмләләр. Һәм ул җөмләләр фәләнешәр кат кабатланган, үз сүзләреңбулып яңгырарлык дәрәҗәгә җиткереп ятланган. Һәм үземнең шулай сабыйларча хыялый булуымнан үзем көлеп җибәрдем.

Һәм янымнан узып барган берәүгә эндәшергә булдым. Тик йөзенә күз салу белән катып калдым. Баягы хыял минем белән шаяра, теге кешенең йөзен бер җыерчыксыз, бер хәрәкәтсез итеп күрсәтә иде. «Курчак!» – дип уйладым котым алынып, тик хыял уйнавын тыеп, чынбарлыкка кайтырга омтылдым.

Бер як читтәрәк сөйләшеп торган төркем ягына атладым. Яннарына барып җитүгә, шат булырга тырышып, яңгыратып сәлам бирдем. Тик миңа берәү дә игътибар итмәде. Алар үзара сөйләшәләр һәм миндә хәбәрләре юк иде. Мин тагы да көррәк тавыш белән кабатладым. Тик бу юлы да игътибарсыз калдым. Өченчесенә бик зәһәр итеп эндәшергә дип авызымны ачтым да… ябарга туры килмәде… катып калдым. Боларның да йөзләрендә бер җыерчык юк иде. Хәтта сөйләшкәндә дә, елмайганда да, көлгәндә дә. Аларның йөзләре шулкадәр матур һәм салкын иде. Һәм мин аларның күзләренә карадым. Йөзләрендә җыерчык булмаган шикелле, күзләрендә дә кешелек әсәре юк.

Кинәт арка үзәгем буйлап салкын йөгерде. Болар кешеләр түгел, ә тере курчаклар лабаса. Һәрбер хәрәкәтләре, сүзләре, карашлары, елмаюлары алдан уйлап, искиткеч төгәллек белән төзелгән, хис-тойгылары да, зиһеннәре дә бары тик үзләренә җитәрлек, үз төркемнәре белән аралашырлык дәрәҗәдә генә итеп бирелгән. Нинди эшләр башкарачагы, нәрсәдер сатып алачагы, нинди сүзләр әйтәчәге, кемнәр белән аралашачагы, кемгә гашыйк булып, кем белән яшәячәге алдан билгеләнгән тере курчаклар. Һәм алар үзләренең һәрбер гамәлен зур төгәллек белән үти, һәрбер вазыйфасын җентекле башкара. Монда хилафлыкка, җитешсезлеккә, ярсу хисләргә, үткен акылга, үзенчәлекле тормышка урын юк. Һәрбер зат ясалма камиллекнең алтын рәшәткәләре артына кертеп ябылган, үзенчәлекләрдән чистартылган, һәркем шәхси төрмәсендә яши һәм үзен иректе шәхес итеп сизә. Урланган кешелеген, югалган гомерен беркем дә уйламый, сагынмый, белми. Һәркем үзен кеше дип уйлый. Һәркем үзен яшим дип белә.

Мин кайттым. Ул мине танымады. Хәтта күрмәде дә.

Марат КӘБИРОВ

САГЫНЫРГА ГЫНА КАЛГАН…

Язмыш

Тәтеш районының Байраш авылында яшәүче 59 яшьлек Миләүшә апа Гайфуллинаның күңеле өзелергә торган яфракны хәтерләтә. Тормышта бик күп хәсрәт күргән ханымның яраларына кагылмыйча, сабырлыгын, көчлелеген зарланудан башканы белмәгәннәргә ачып бирәсе иде. Еламый түгел, елый, бугазына төере дә утыра, әмма яшәргә көч таба ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Миләүшә өч-дүрт яшьлек чагында әтисен югалткан, 15 яшендә әнисез калган. Дүрт туганының бүген өчесе исән. Харис абыйсы дүрт ел элек гүр иясе булган. Армиягә киткән җирдән Чита өлкәсендә өйләнеп калган газиз энесе Әкрамын 25 ел күргәне юк аның. Шушы вакыт эчендә ике генә мәртәбә күрешкәннәр. Дөрес, туганлык җепләре өзелмәгән, телефон аша аралашып торалар. Әмма энесен бик нык итеп кысып кочаклыйсы килгән чаклары да була Миләүшә апаның. Ике ел элек ире Кәбир мәңгелек йортка күчкән. Аны искә алмаган көне юк. Балалар сөяргә дә язмаган аңа. Күпме генә хәсрәтләр кичерсә дә, язмышына рәнҗеми. Барысын да Аллаһ сынавы дип кабул итә.

– Әтидән 3–4 яшьлек чакта калганмын. Ул бик булдыклы тимерче булган. Колак алкалары ясаган. Сәгатьләр ремонтлаган. Авыл халкының гозере еш төшкән аңа. Әтием турында яшьтәшләре, шулкадәр алтын куллы иде, дип сөйләде, – ди Миләүшә апа Гайфуллина. – Әни үлгәндә, миңа 15 яшь иде. Аның тезләрендә ревматизм чире таптылар. Операция дә кирәк булгандыр, бәлкем, белмәдек бит, белмәдек. Ул вакытта халык хәзерге кебек белемле түгел иде шул. Буыннары авыртып, ике ел урын өстендә ятты. Әнине абыем Харис бик тәрбияләде. Мунчага күтәреп йөрттек. Шулай итеп, безгә әти-әни кочагына сыенып үсәргә язмады. Язмыш камчысы исә үткен иде.

Шулай итеп алар дөм ятим кала. Апалары Казанда яшәгән. Авырлыкның юан башы абыйсы Харис, энесе Әкрам һәм Миләүшәгә төшкән.

– Акча юк. Бишәр ипи пешерә идем. Абый белән энем хуҗалык көтүен көтте. Киемнәре юешләнеп кайта, мин киптерә идем. Юньле ыштан да кимәдек. Харис абый кырда печән чаба иде. Хәзер мал асраган кешегә бик рәхәт. Печән-саламын капка төбенә кадәр китереп бирәләр, – ди Миләүшә апа, ятимлек ачысын искә төшереп. – Абыйны армиягә алгач, энем белән икәү калдык. Ул, кайтып, Тәтешкә урнашкач, энемне дә хәрби хезмәткә чакырдылар. Мин авылда төп йортта үзем генә яшәдем. Ничек тә булса тамак туйдырырга кирәк. Сыерлар, үгезләр асрадым. Бәрәңге утырттым. Тырышкач, дөнья көйләнде тагын. 10 нчы сыйныфтан соң укырга барырга насыйп булмады инде. Фермада сыер саудым, бозауларны саклап, каравыл тордым. Сөт эчерә идем. 24 яшьтә авыл егете Кәбиргә кияүгә чыктым. Төп йортның ишегенә йозак элүнең нинди кыен икәнлеген белсәң… Шуннан соң инде нигезгә яшәргә кайтучы булмады.

Миләүшәнең ирдән бәхете була анысы. Тракторчы булып эшләгән Кәбирен, бик тырыш иде, дип искә ала. 33 ел тигез, тату тормышта яши алар. Баласызлык мәхәббәткә киртә булмый. Хәзер инде барысын да сагынырга гына калган. Кәбире 58 яшендә йөрәк чиреннән дөнья куйган. Бик яраткан үзен. Ире рухы тыныч булсын дип, намазга баскан. «Ике ел үтсә дә, бик авыр, бер дә оныта алмыйм. Әйбәт кеше иде», – ди ул.

Авырлыкларны хезмәт белән җиңәргә тырыша Миләүшә апа. Сыер асрый, суясы үгезе бар. Ишегалдында кош-корты чабыша. Мал азыгы кыйммәт дип, терлеген бетерергә җыенмый. Эш белән үткән көндә мәгънә бар чөнки. Пенсиядә булса да, клубта җыештыру эшен дә ташламый. Анысы – үзе бер юаныч. Диннең дә шифасын тоя. Догалар тынычландыра, яшәргә көч бирә, ди. Күршеләрен, дусларын әйбәт дип мактый. Алар – тормышта бер терәк. Сөенеч-көенечен уртаклашырга, бергәләп чәй эчәргә ахирәтләре бар, шөкер.

– Табында ризык мулдан. Ил-көннәребез тыныч булсын. Хәрби операциядә катнашучы ирләр исән-сау гаиләләре янына әйләнеп кайтсын. Балалар әтиле үссен. Кылган догаларым шул хакта да. Берәүгә дә безнең кебек ятимлек ачысы татырга язмасын, – дип тели Миләүшә апа Гайфуллина.

Сәрия МИФТАХОВА

БӘХЕТЛЕ БУЛ, БАЛА…

Чын хикәя

Йокыдан күтәренке кәеф белән уянды Зөлфирә. Күзен ачуга, Аллаһы боерса, бүген улым кайта бит дип, җаны-тәне белән сөенеп, урыныннан кузгалды. Гадәт буенча, исән-сау йоклап торуына, тыныч-имин төннәргә шөкер итеп, хәерле көннәр туган булсын, хәерле хәбәрләр генә ишетергә насыйп булсын дип, теләкләрен теләргә дә онытмады.

Яше олыгаеп барса да, әле сәламәтлектән зарланмый. Аягы-кулы йөреп тора, вак-төяк сызланулар, авырту-сырхаулар булып торса да, «Яшең алга баргач, булыр инде ул», – дип, үзен юата. «Әни, әйдә инде безнең белән», – дигән балаларына да: «Көчем беткәч, үзем әйтермен, әлегә үз өемдә үз көемә яшим», – дип, ипләп кенә кире кагып килә.

Ике улы инде гаиләле. Төпчеге Раил дә утызын тутырып килә. 40ны үткәч тапкан Раиле – нәкъ әтисе Камилнең копиясе. Төс-кыяфәте, холкы белән дә. Әтисен өлкәннәр сөйләгән буенча гына белеп үссә дә, гаҗәп менә, Раил бөтен гадәте белән аны кабатлый. Бөтен эшкә кулы ятып тора. Ул йөрешләре, сөйләшүләре дисеңме…

Мәктәптә бик җиңел укыды, әнисенең йөзен кызартмады Раиле. Аттестатында «бишле»ләре күбрәк булса да, мәктәп тәмамлагач: «Берәр һөнәр алам да авылда калам, сине ялгыз калдырып китмим», – дигән иде. Зөлфирә аяк терәп каршы торды: укыйсың. Мин әле көчемдә. Сау-сәламәт. Атна саен кайтып йөрерсең. Авыр эшләрне кайткан-киткән арада эшләрсең. Син генә түгел бит, абыйларың, аларның гаиләләре дә бар. Алар да кайтып тора…

Соңгы курста улларын зур бер заводка практикага җибәрделәр. Дүрт айлык практикада ул андагы кешеләр белән дуслашып бетте. Диплом алуга, үзебезгә кил, эшкә алабыз, дисәләр дә, улы тагын авылга кайтырга теләвен әйткән иде. Зөлфирә: «Әлегә эшләп тор. Мин ялгызым яши алмый башлагач кайтырсың», – диде. Улының күңелен сүрелдерер өчен генә әйтте инде ул бу сүзләрне. Унике йортлы авылга кайтып, әллә ниткән катлаулы замана җиһазларын көйләүче инженер дипломы белән нишләр ди ул?!

Ике арага тузан кундырмады анысы Раиле. Атна саен кайтмый калмады. Акчага да тилмертмәде, әйбер эзләп тә, эшләргә кеше эзләп тә йөрмәде Зөлфирә. Раил, Казаннан торып, атна уртасында да аның тормышын алып бара иде. Абыйлары гаиләле булгач, өйне, әнисен карау миңа күбрәк тиеш, дип тырышты. Әле менә бер ай элек Мәскәү өлкәсенә командировкага җибәрделәр үзен. Моңа кадәр атна саен күрешеп торгач, бер ай бер гомер кебек тоелды Зөлфирәгә. Телефоннан көнгә әллә ничә тапкыр сөйләшсәләр дә, кара-каршы утырып сөйләшүгә җитәмени соң?!

Әнә улы кайтып та җитте. Шулай гадәтләнде ул, капка төбенә кайтып туктый да машинасын: «Ә-ни, мин кайт-тым», – дип, өзек-өзек кычкыртып ала. Раилнең кычкыртуын башка бер генә машина тавышы белән дә бутамый Зөлфирә. Машинасы «пип-пип» дип кычкырса да, әни кешегә ул талгын гына кычкырту: «Ә-ни, мин кайт-тым», – дип ишетелә. Раил үзе шулай дип кычкыртам ди ләбаса. Капканы ук ачып көтмәсә дә, өйдә үзен көткәннәрен белсеннәр дип, Зөлфирә улы эштән чыгар вакыт җитүгә, болдыр башындагы утны яндырып куя. Заманча прожектор бөтен ишегалдын тутырып, улы кайтышка бәйрәм рухы биреп тора.

– Мине бу өйгә кертәләрме икән инде дип кайткан идем, элеккечә үк көтәләр икән әле, име, әни!.. – Машинасының ишеген дә япмыйча, әнисен кочагына алган улы шулай диде. – Сагынып беттем, әниии…

– И улым, минем кадәр үк сагынмагансыңдыр әле, – димәкче иде Зөлфирә. Тик: «Сиздем мин аны. Мәскәү тирәсендә бер кечкенә малай әнисен сагынып еламсырап йөри иде», – дип, шаяруга борды.

– Самолеттан төшүгә кайтмаганга үпкәләмәгәнсеңдер бит, әнкәй? – Игътибарлы улы әнисе йөзендәге кичерешләрне күрми кала димени.

– Юк ла инде, улым. Төшүгә шалтыраттың, эшемә кереп чыгуга кайтырга чыгам, чәеңне куя тор, дидең… Хәбәреңне, кайдалыгыңны белеп торгач, бик риза инде мин. Әйдә, юлдан кайткач ашамаган да бит син, ашым пешкән, чәем кайнаган… Өйгә кергәч сөйләшербез калганын.

Аш өстәле артына кара-каршы утыргач та, Зөлфирә улының текәлеп-сөеп караган күз карашын тоеп-сизеп торды. Үзгә, бөтенләй башкача карый иде ул. Дөрес, моңа кадәр дә ана җанлы, бик миһерле бала булды. Төпчек булгангадыр да, әнисе янында бөтерелеп үсте. Зур үскәч тә, әнисен борчымаска, сөендерергә тырышты. Тик бүген ул бөтенләй башка төрле иде.

Зөлфирәнең йөрәге кинәт ашкынып тибә башлады. Улыма нидер булган. Нидер әйтәсе бар кебек. И Раббым, борчулы хәбәр генә булмасын. Эче тулы ут булса да, улы үзе сүз башламыйча, берни сорамады, түзде әни кеше.

Гадәттәгечә, тамак туйдыргач, ана белән бала залдагы диванга күченде. Аларның иң яраткан урыны ул. Мәктәптә укыган чакта да, студент вакытта да, әле дә шунда утырып, озаклап, тәмләп гәпләшергә яраталар.

– Әни, хәтерлисеңме, мин сиңа бервакыт таныш кызның гаиләсе белән авариягә очраулары, әнисенең үлүе, үзенең бик күп операцияләр кичерүе турында сөйләгән идем. Күптән күргәнем юк иде, бүген аэропортта шуның белән очраштык. «Себергә күченеп киттем. Монда яши алмадым. Әнисез бик авыр булды, – ди. – Авылга кайтсам, бөтен нәрсә әнине хәтерләтә, елап, тилерер хәлгә җитәм, зиратка барсам, алып кайта алмыйлар… Аптырагач, авылга кайтмый кара, диделәр. Казанда да үземә урын таба алмадым. Туганнарым Себергә алып китте. Ике елдан соң беренче тапкыр кайтам. Өйдә әни көтәдер кебек тоела… Белмим… ничекләр әнисез өйгә кайтып керермен… Әниеңне сакла, ярат, кадерлә», – диде…

Раил бу сүзләрне әйткәндә кичерешләрен яшерергә, ничек тә күз яшьләрен әнисенә күрсәтмәскә тырыша иде. Тик ана күңеле сизми димени?!

…Менә нәрсәдә, менә кемдә икән хикмәт, дип нәтиҗә ясады Зөлфирә. Ул инде әлеге миһербанлы кызны яратып та өлгергән иде бугай. Бер сөйләшүдә улының күңеленә күпме наз, күпме җылылык тутырган лабаса! «Безгә насыйп килен булсаң, мин сиңа кызым диярмен», – дип куйды ул күңеле белән.

Тик, әнисенең күңелендәгесен сизгән кебек, улы: «Кияүгә чыга ул, үзе генә түгел иде, булачак ире белән дә таныштырды… Әтисенең фатихасын алырга кайтышы… Һәм… әнисенекен дә…» – диде.

– Бәхетле бул, бала! – Зөлфирә бу сүзләрен инде уйлап кына калмады, бар йөрәге белән, әниләрдә генә була торган ихлас бер җылылык белән кычкырып әйтте. Күңеле, йөрәге генә түгел, бу минутларда аның һәр күзәнәге исеме дә билгеле булмаган, таныш түгел кызга бәхет тели иде…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ГӨМБӘЧЕ ЧУЛПАН ӘҮХӘДИЕВА:

«Елга 700 банка гөмбә сатам»

Балтач районының Арбор авылында яшәүче Чулпан Әүхәдиева ире белән бер баруда сигез чиләк майлы гөмбә җыйган. «Шулкадәр күп, урак белән урырлык иде», – ди ул. Уңган хуҗабикә төн буе шуны чистартып, плитә янында кайнашса, иртәгесен тозлап, кичкә сатарга да өлгергән. 60 банка гөмбәнең берничәсе генә калган.

– Менә әле гөмбә сатып кайтып килеш. Тизрәк кайтып җитеп, тагын урманга чыгып китәргә исәп. Башымда шул гына уй. Бер атна элек усак гөреҗдәсе җыйдым. Яңгыр яву-яумауга карамый ул. Аз гына чык төшсә дә үсә һәм кортламый да. Гөмбә җыю үзе бер чир кебек. Кечкенәдән әни белән җыеп үстем. Гөмбә ашарга әллә ни исем китми. Әмма җыю процессы ошый. Кичә дә ирем Илфар, җитәр инде, тукта, ди. Ә мин туктый алмыйм. Өйгә кайткач чистартасын да онытып җибәрәм, – ди Чулпан.

Әүхәдиевләр авылда кибет тота. Ярымфабрикатлар ясап саталар. Ә гөмбә бизнесына 4–5 ел элек күчкәннәр. Бер тәмен белгәннәр ел саен күпләп сатып ала икән. Социаль челтәрләргә куйган тозлы гөмбәсенә шәһәр халкы да кызыга. Казаннан кадәр килеп алучылар да бар. Тик бөтенесенә дә җитми шул. Сүз уңаеннан, ярты литрлы банкадагы гөмбә 250 сум тора. Табышы йорт кирәк-ярагына тотылып бетә, ди хуҗабикә. Бер елны 700 банка тозлап саткан.

– Күп кеше гөмбә җыя белми. Ләкин ашарга яратабыз, диләр. Киңәшем шул: шикле гөмбәгә бөтенләй кагылмаска кирәк. Мин авыл урманыннан үзем белгәнен генә җыям. Тозлаган гөмбәмнән агуланмаячакларына ышанам. Ни өчен дигәндә, бөтен шартын туры китереп тозлыйм. Банканы сузгач, иң беренче сүзем шул: «Барысын да күрмәгәндәй берьюлы ашап бетерәсе түгел». Башлаган банкада гөмбә калган очракта аны сыек май белән туглап куегыз. Тик икенче көнгә ашап бетерегез. Гөмбәне 1–2 көннән артык торарга ярамый, – ди Чулпан.

Хәзерге вакытта башка гөмбәләр бик күренми икән. Көз башында, яңгырлар явып үтсә, җирән гөмбә (рыжик) чыгачак. Өч-дүрт ел элек Чулпан баллы гөмбәне (опята) капчыклап җыйган. Соңгы вакытта анысы очраганы юк, ди.

Чулпан ӘҮХӘДИЕВАдан майлы гөмбә (маслята) тозлау рецепты:

– Майлы гөмбәне чистартам. Өстенә су салып кайнатып, бер кат түгәм. Икенче тапкыр кайнатып чыгаргач, 1–2 баш укроп, лавр яфрагы, 3 кашык тоз өстим. Аны сөзгәч, банкага тутырганда, өч аш кашыгы серкә һәм хуш исле бер данә борыч салам. Сарымсак салмыйм, ул әчетә. Гөмбәне салкын җирдә саклыйм.

Сәрия ХАФИЗОВА

ИЛГИЗ МӨХЕТДИНОВ: «СӘХНӘДӘ НИНДИ – ТОРМЫШТА ШУНДЫЙ»

Манзара

Сәхнәдәшләреннән үз йөзе, кабатланмас тавышы, белемгә омтылышы, үзенчәлекле зәвыгы белән аерылып тора ул. Сүзебез – җырчы Илгиз МӨХЕТДИНОВ турында. Аның белән җыр-моңга мәхәббәт, мәгънәле һәм мәгънәсез җырлар, көндәлек тормышта нинди булуы турында сөйләштек.



:: Илгиз, татар җыр сәнгатенә ныклы адымнар белән килеп кердең син. Җырчы булу теләге кечкенәдән үк киләме?
– Балалар бакчасыннан ук җырлый башладым. Ике егет, дүрт кыз белән ансамбльдә уйный идек. Җыр белән мавыгуым, сәнгать, иҗатка тартылуым мәктәптән башланды. Җырчы булу теләге дә мәктәптә укыган чакта, беренче укытучым – Зөлфия Хәким кызы Фәйзрахманова белән шөгыльләнгән вакытта барлыкка килде. Ул миңа халык җырларын, иң авыр җырларның берсе – «Тәфтиләү»не дә өйрәтте. Җыр-моңга мәхәббәт гаиләдән дә киләдер инде. Без дәү әни белән дәү әти карамагында үстек. Әниләр һаман эштә иде. Әнинең апасы безгә җырлар өйрәтте. Хәйдәр Бигичев, Салават Фәтхетдинов җырларын өйдә, гаилә бәйрәмнәрендә җырлый идек. Хәйдәр абый – минем өчен эталон ул. Көллияттә укыган вакытта да аны тыңлап, аннан карап өйрәнә идем.

> Әти телгә карата кырыс булды. Өйдә татарча гына сөйләшергә ярый иде. Урамга чыксаң, теләсә нинди телдә сөйләш, ә өйдә – туган тел генә.

:: Син сәхнәдә башкаларны кабатламыйсың, репертуарың да үзенчәлекле. Җыр сайлаганда иң беренче чиратта нәрсәгә игътибар итәсең?
– Иң мөһиме – сүз. Аңлатасы килгән хисләрне сүз аша җиткерәбез. Сүз белән үтереп тә була, дип юкка гына әйтмиләр. Аннан бөтен нәрсә шигырьдән тора. Минемчә, шагыйрь аны язган чакта ук ниндидер көй белән яза. Әлбәттә, композитор эше дә бик мөһим. Ул үз көен куша һәм идеаль тандем килеп чыга.

:: Иҗатыңны халыкка ничек җиткерергә? Аның сере бармы?
– Иң беренчесе – туйганчы йокларга. Чөнки арыган кеше яхшы эшли алмый. Икенчедән, ирек кирәк. Үз фикерләреңне, уйларыңны, идеяләреңне җиткерүдән курыкмаска, кысалардан арынырга кирәк. Әлбәттә инде, тавышны гел тонуста тотарга, зыян китермәскә. Профессиональ җырчы гел үз өстендә эшләргә тиеш.

:: Хәзер күп кенә яшь башкаручылар, артист булыр өчен укып торырга кирәкми, дигән фикердә. Консерватория тәмамлаган җырчы буларак, синеңчә, музыкаль белем кирәкме?
– Төрле кеше бар. Кемгәдер сәләт тумыштан бирелгән. Шулай да, җырчыларга музыкаль белем алырга кирәк, дип уйлыйм. Уку артык булмый ул. Тарихны өйрәнәсең, профессиональ яктан ныгыйсың, төрле музыка коралларын үзләштерәсең. Матур итеп чыгып басып җырлау – бер хәл. Кыяфәткә карап каршы алалар, ә бит акылга карап озаталар. Берәр әңгәмә вакытында, әйтик, югары музыка турында сөйләшкәндә, кемнең кем икәне аңлашыла инде. Музыка теориясен белү дә мөһим, чөнки музыкантлар белән эшләгәндә син – аларны, ә алар сине аңларга тиеш. Уку йорты белән генә дә чикләнергә ярамый, алга барырга, камилләшергә кирәк.

:: Эстраданың җиңеләюе турында нәрсә уйлыйсың? Бу шартларда син ничек «исән каласың» (яшисең)?
– Мин бит танылган эстрада җырчысы түгел. Син артист, шәхес икәнсең, халыкка, киләчәк буынга үзеңнән соң мәгънәле әйбер калдырырга тиешсең. Ниндидер фикер, идея булырга тиеш. Миңа иң мөһиме – җыр матур һәм эчтәлекле булырга тиеш. Ул бүгенге тенденцияләргә туры килмәсен, ә үземә ошасын. Һәрбер кеше үзенчә эшли. Һәркемнең үз тыңлаучысы бар. Кемгәдер җитдирәк җырлар кирәк, кемгәдер күңел ача торган булсын. Кызыклы итеп, төрле форматларда һәм төрле жанрларда эшләп карарга кирәк. Мин эстрада җырларын гына түгел, романслар да җырлыйм, академик вокал белән шөгыльләнәм. Ретро-җырларны яңартасым килсә, аларны бик нык үзгәртмим, фикерен калдырам.

> Иҗатны сайлагансың икән, син аңа сак карарга тиеш. Кыяфәтең белән дә, җырларың белән дә шушы өлкәгә туры килергә кирәк.

:: Ә синең үз тыңлаучың бармы?
– Тыңлаучылар бар, әлбәттә. Социаль челтәрләрдә язып, фикерләрен җиткереп торалар. Төрле мәйданнарда чыгыш ясаганда да, килеп күрешәләр, җылы сүзләр әйтәләр. Минем аудитория – башлыча 17–30 яшьлекләр. Социаль челтәрләрдәге статистика буенча карасак та, шулай килеп чыга. Чөнки җырларым күбрәк мәхәббәт, туган илебез турында. Концертларны өлкәннәр дә ярата. Аларның барысына да бик зур рәхмәт. Әле кемдер махсус мине күрер өчен килә. Шундый хәл дә булган иде: Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе белән бервакыт Кукмара районына бардык. Балалар программасы иде ул. Килдек, ләкин ниндидер авырлыклар аркасында, әллә көнен бутаганнар иде, концертны күчерергә булдылар. Шул вакытта 12 яшьлек бер кыз: «Мин бит сезнең өчен килдем монда», – дип, каршыма чыкты. Аны утырттым, нинди җыр телисең, бөтенесен җырлыйм, дидем. Шулай итеп, махсус шул кыз өчен 2–3 җыр җырлап киттек.

:: Моң – синең өчен нәрсә?
– Бик авыр сорау. Аны хис дип тә, ирек дип тә әйтеп була. Сүз белән аңлатып, әйтеп булмый торган кичереш. Өч хәрефле генә сүз, ә эчтәлеге, мәгънәсе бик киң.

:: Тавышыңның көче нәрсәдә дип уйлыйсың?
– Практикада. Эстрада җырларын җырлау җиңел, әйтик, арияләрне башкару бөтенләй икенче. Операда 1 генә түгел, 4–5 ариягә хәтле җырларга туры килә, әле 1–2 дуэт та эләгергә мөмкин. Операдан соң икенче көнне концертка баргач, үземне ничектер җиңел хис итәм. Чөнки монда андый нагрузка булмаячак. Һәм, әлбәттә, җырлаган чакта спорттагы кебек, иң мөһиме – дөрес сулау.

:: Син сәхнәдә дә, көндәлек тормышта да бертөрлеме?
– Сәхнәдә нинди, тормышта да шундый мин. Сәхнәдә үз йөзеңне югалтырга ярамый. Тормышта да шулай. Ләкин сәхнәдә булганда сине карыйлар, күзәтәләр. Ә тормышта күләгәдә каласың. Аның шулай булуы әйбәтрәк һәм җиңелрәк тә. Хәзер бит социаль челтәрләрдә дә бөтен нәрсәне күреп була. Качсаң да, качмасаң да, барыбер нинди икәнеңне беләчәкләр. Холкым буенча йомшак, тыныч кеше мин. Ачу чыкса, бер чыга инде ул. Мин – күбрәк тыңлаучы, сөйләүче түгел. Гастрольләргә чыгып киткәндә дә, күбрәк тыңлап утырырга яратам. Гади тормышта якын дусларым белән күрешергә тырышам. Эстрадада дусларым күп. Тату, бер-беребезгә булышып яшәргә тырышабыз. Алар арасыннан Филүс Каһировка аерым рәхмәт әйтәсем килә. Аның группасына консерваториядә укыганда килгән идем, бүген дә анда җырлыйм. Бишенче ел була инде. Һаман булышып тора, сүз белән дә, фикер белән дә, җыр ягыннан да.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Афиша

Кызу август

Җәйнең соңгы аенда кая барып, ниләр күрергә? Бу сорауга җавап таба алмый йөрисез икән, түбәндәге чаралар исемлеге белән танышырга тәкъдим итәбез.

КАЗАН

2 августта (ягъни бүген була инде ул) Горький исемендәге паркта «Тормыш агачы» проектының татар мәдәниятенә багышланган чарасы узачак. Тамбурлы чигү, Казан җөе, керамика, баш киеме ясау, музыка уен коралларында уйнарга өйрәтү һәм башкалар буенча остаханәләр әзерләнгән. Кунакларны Чувашиянең Урмай авылыннан «Мишәр» халык фольклор-эстрада ансамбле, Субаш авылының «Нардуган» керәшен халык фольклор ансамбле, «Риваять» этно-төркеме, «Zakaria» фолк-төркеме һәм мультиинструменталист Илмир Ямалов чыгышлары көтә.

12 августта шушы ук паркта Идел буе халыкларының заманча мәдәниятенә багышланган «Итил» фестивале башланачак. Идел буе шәһәрләреннән килгән җирле артистлар катнашындагы зур гына программа көтелә.

16 августта шушы ук урында өлкән буын вәкилләрен махсус бәйрәмдә – Тормыш сөючеләр көнендә көтеп калалар.

26 августта – Республика көне алдыннан «Казан тавышы» музыкаль-театральләштерелгән перформансы узачак. Мэрия балконыннан Казан театрлары актерлары татар һәм рус шагыйрьләренең әсәрләрен укыячак.

Шул ук көнне Кабан күле буенда «Печән базары» фестивале узачак.

Һәр атнаның пәнҗешәмбесендә (җәй азагына кадәр) 18.00 сәгатьтә Камал театры янындагы мәйданчыкта «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты җырлы-биюле чаралар уздырачак.

Көн саен Казанның Бишбалта бистәсендә ачык һавада автокинотеатр эшли. Фильмнар гына түгел, мультфильмнар да күрсәтәләр анда. Билет бәясе – 300 сум.

ЧАЛЛЫ

12 августта автокала Төзүчеләр көнен билгеләп үтәчәк. Зур кунаклардан «Синяя птица» вокаль-инструменталь төркеме һәм «Пицца» төркеме чакырулы икән.

19 августта Чаллының «URBANTATAR» шәһәр җәмгыяте «UT FEST» яңа татар мәдәнияте фестивален уздырачак. Ул шәһәрнең Азатлык мәйданында 12.00 сәгатьтә башланып, 22.00 сәгатькә кадәр дәвам итәчәк.

Һәр атнаның пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә «Арт-площадь» проекты кысасында төрледән-төрле чаралар булачак. «КамАЗ» мәдәният сарае каршында остаханәләр, дискәтүкләр, иҗади кичәләр узачак.

ТҮБӘН КАМА

4 августта Тукай исемендәге паркта җырчы Рафаэль Якупов чыгыш ясаячак.

5 августта Лемаев исемендәге скверда «Шанс» иҗади берләшмәсе чыгыш ясаячак.

6 августта «СемьЯ» паркында Кристиан Апостол атлы рәссамның күргәзмәсе эшләячәк. Кичке якта баянчылар Айнур Моратов, Әлфис Галиуллин һәм яшь җырчы Илүзә Гайсина чыгыш ясар дип көтелә.

12+

КЕМ СИН, МИКУЛАЙ?

ТАТАРСТАНДА ТӨШЕРЕЛГӘН ЭТНО-ТРИЛЛЕР ТУРЫНДА УЙЛАНУЛАР

Премьера

Мансур Гыйләҗевнең монопьесасы буенча төшерелгән «Микулай» – елның иң көтелгән фильмы, дисәк, ялгыш булмастыр. Илшат Рәхимбайның этно-триллеры прокатка чыгып, илнең 150дән артык кинотеатрында күрсәтелде. Керәшеннең җан ярасы булган «Микулай» өметләрне акладымы? Фильмны «ВТ» хәбәрчеләре дә карады.


kino-teatr.ru

«Керәшен мәдәнияте монда бөтенләй юк»

Прокатка чыккан көннән алып һәм хәтта алданрак та фильм турында төрле фикерләр булды. Кемгәдер ул ошады, кемдәдер эчтәлеге авыр һәм аңлатып булмаслык хисләр тудырды, кемдер инде идеясеннән үк канәгать түгел иде. Аңлашыла, соңгылары күбрәк керәшен татарлары иде. Ни өчен дигәндә, фильм төшерелгәндә үк: «Керәшен темасына кагылган фильм безнең белән киңәшләшмичә төшерелә», – дип, ризасызлык белдерде алар. «Керәшенлек монда бөтенләй юк, өйрәнелмәгән, безгә бөтенләй дә хас булмаган нәрсәләр болар», – дип ачындылар. Ә белгечләр, чыннан да, кирәк булган. Урыны-урыны белән артык фантазиягә бирелгәнлек, кайбер күренешләрнең абсурд дәрәҗәсенә җиткерелүе сизелде. Кем әйтмешли, кычкырып көлеп тә җибәрәсе, елыйсы да килде. Өй капкаларындагы, бүрәнәләрдәге, биналардагы рәсемнәрне генә алыйк. Алар сектантлык билгеләре сыман бик ясалма тоелды.

Ни рәвешле булса да, фильмда керәшен мәдәниятенә урын бирелгән. Керәшеннәр – милли киемнәрдән, алар башкарган җырлар – керәшен фольклоры, сөйләмнәрендә – рус исемнәрен үзләренчә үзгәртеп сөйләүләр (фильмда татарча да сөйләшәләр). Сарсаз Күл авылында барган вакыйгаларда керәшен йолалары, гореф-гадәтләре белән дә таныштык.

Этноста триллерга урын бармы?

Хәзер бераз жанр турында. Триллер – тамашачыда яки укучыда борчылу, дулкынлану яки курку хисләрен уятуга юнәлтелгән әдәбият һәм кино жанры. Бирелә исә Микулайның саташулы халәте триллер форматына китерелгән. Туган җире, тамырлары, халкы булмаса, кешенең киләчәге булмаячак. Элеккеге заманнар, югалган вакыт, авылдашлар турындагы хатирәләр Микулайның бөтен тормышын җимерә, аны акылдан яздыра. Фильмның жанры триллер гына түгел, этно-триллер. Ягъни халык турында маҗаралы, куркыныч фильм булып чыга…

Мансур Гыйләҗев «Микулай»ны дөнья корылышының төп сорауларына кагылышлы җитди фильм дип атады.

– Без сезгә комедия күрсәтмибез. Дөнья корылышының төп сорауларына кагылышлы җитди фильм күрсәтәбез. Илшат Рәхимбай көчле режиссерлык осталыгына ия. Никита Михалковның: «Чын режиссер теләсә кайсы актерны бер шоколад өчен аның фильмында төшәргә күндерә ала», – дигән сүзләре бар. Илшат моңа сәләтле, – диде драматург прокатның беренче көнендә.

Продюсерларның берсе **Диана Сәфәрова,** фильмнан һәркем үз мәгънәсен табачак, дигән фикердә.

– Фильм бөртекләп җыелды, шулай да ул бик күп катламлы. Бу – җитди кино. Илшат Мәскәүдә фильмны тәкъдим итү чарасы алдыннан: «Бөтен матрица законнары буенча бу фильм булырга тиеш түгел», – дип әйткән иде. Мин, киресенчә, ул булырга тиеш иде, дип саныйм. Чөнки бу фильм – ышаныч турында. Моңа Илшатның сәләтенә, бу картинаның мөмкинлегенә ышану да керә. Мөгаен, шуңа күрә барысы да килеп чыккандыр, – диде продюсер.

«Фильм минеке түгел»

Билгеле булганча, фильм – рус телендә. Төп рольне башта татар актерына биреп, татарча кино төшерү турында уйлаганнар. Соңрак, Виктор Сухоруков, Иван Добронравов, Варвара Шмыкова, Екатерина Агеева кебек Россиянең танылган актерларын чыкырып, кинокартина рус телендә төшерелгән. **Илшат Рәхимбай** әлеге фильм өчен Виктор Сухоруковның дүрт проекттан баш тартуын да искәртте.

– Өч ел дәвамында без «Микулай» проекты белән яшәдек. Төшереп бетергәч тә, безнең өчен бөтенләй яңа тормыш башланды. Чөнки без әле аны ничектер тамашачыга җиткерергә тиеш идек. Һәркем үз миссиясен тойды. Бу фильм минеке түгел, аның үз язмышы бар. Бу команданы җыю, фильмны төшерү һәм аны сезгә күрсәтү бәхете нәкъ менә миңа насыйп булды, – диде ул премьера көнендә.

«Микулай» – ялгызлык трагедиясе

Фильмның үзенә күчик. Микулай – Сарсаз Күл авылында берьялгызы тормыш итүче керәшен карты. Аның тыныч тормышына көтмәгәндә улы Степан килеп керә. Шуннан соң Микулай дөньясының асты өскә килә. Искәртеп узыйк: Мансур Гыйләҗев пьесасы буенча республиканың ике театрында (Әлмәт һәм Кариев театрлары) моноспектакль куелды. Керәшен Микулае образы аша дөнья проблемалары – туган телләр, авыллар, халыкларның бетүе, гаилә кыйммәтләре, кешелекнең хиссез курчакларга әверелүе күрсәтелде. Тик спектакльдәге Микулай белән фильмдагы Микулай – икесе ике герой. Фильм Микулае – психик тайпылышлы, әхлаксыз, үз нәселен юк итүче, акылдан язган.

Микулайның «әңгәмәдәш»ләре – үз уйлары, җансыз курчаклар. Әти-әнисе, балачак дуслары, хатын-кызлар, авыл тормышы, үлем – Микулайның ялгызлык халәте бар нәрсәне барлый, аның үткәннәрне җибәрәсе килми. Җансыз сыннар белән сөйләшкән кебек тоелса да, ул аларны чын, тере итеп күрә. Шул рәвешле режиссер аның мисалында ялгызлыкның нинди булуын күрсәтә.

Ни өчен керәшеннәр?

Әйтергә кирәк, күпчелек кеше Микулай образының керәшен итеп бирелүенә аптырады. Монда аерым бер халык турында сүз бармый, керәшеннәр турында аерып күрсәтелми, дигән фикерләр әйтүчеләр дә бар. Бу сорауга Илшат Рәхимбай җавап бирде.

> Беренчедән, Мансур Гыйләҗевнең пьесасында – керәшеннәр, вакыйгалар керәшен авылында бара. Мансур абый үзе дә керәшен авылында үскән, шуңа монда бу халык мохите бар. Бу аларга рәхмәт йөзеннән язылгандыр. Мансур абыйның бу әсәре башкаларыннан нык аерыла. Укып чыккач, миңа шок булды. Экранда моның тагын да көчәячәген тойдым. Керәшен мәдәнияте экранда бик колоритлы чыга – минем өчен бу әһәмиятле иде. Әсәр нәкъ менә керәшен авылында гына идеаль ачыла алыр иде. Микулай тарихы ул – керәшен кешесенең тормышы гына түгел, гомумән, ялгыз кешенең трагедиясе. Фон булып керәшен дөньясы тора, – диде ул.

Иге-чиге булмаган фантазия арасыннан төп фикерне табарга кыен. Фильмның глобаль идеясе нинди соң? Илшат Рәхимбай бер төп идеяне генә тартып чыгарасы килмәвен әйтте.

– Фильм күпкатлы. Ул катлаулырак чыкты, шул катламнардан һәр тамашачы үзенә якынын уйлап таба. Фильмның уникальлеге шундадыр, – диде режиссер.

«Болай булыр дип көтмәгән идем»

Кино белгече, тәнкыйтьче Әдилә Хәйбуллина премьерадан соң фильмга әнә шундый бәя бирде.

– Мин фильмнардан бик сирәк тәэсирләнәм. Бу фильм гаҗәпләнү хисе тудыра алган сирәк бәхетле мизгелләрнең берсен бирде. Гадәттә, милли драматургияне экранга күчерү сюжетны сурәтләүгә генә кайтып кала. Чөнки һәр кеше беренчел чыганакка сак карый. Кино ул – сәнгатьнең бөтенләй башка төре. Илшат тамашачы белән заманча кино телендә сөйләшә. Бу иллюстрация дә, адаптация дә түгел. Бу – нәкъ менә кино теле белән сөйләнелгән тарих, – диде ул. – Илшатта тоемлау һәм хәзерге кинематография трендларын һәм тенденцияләрен аңлау сәләте бар. Ул, чыннан да, гаҗәеп зур эш башкарган. Фильм метафоралар белән тулы, визуаль тел һәм искиткеч актерлар эше белән ныгытылган. Һәм, әлбәттә, жанр белән эшләү. Монда – жанрлар концентрациясе. Башта без триллер карыйбыз, аннары ул психологик драмага әверелә, хоррор, этно элементлары бар. Боларның барысын да берьюлы карау кызыклы, чөнки бу – чын кино, ул төрле яссылыкта эшли. Яңа Татарстан киносы феномены «Микулай» картинасыннан башланачак, дип уйлыйм. Бу – Татарстан өчен генә түгел, Россия кинематографы өчен дә зур вакыйга.

Кем син, Микулай?

Хәзерге заманда һәр күренешне психологик яктан өйрәнү киң таралган. Шулай итеп, «Микулай»дагы Микулайның кем икәнен психолог белән бергә ачыкларга тырыштык.

Клиник психолог Алия Булатова фильмның төп героена «шизофреник» дигән диагноз куйды. Моны бөтен билгеләр дә күрсәтә, ди.

– Фильм шартлыча сәламәт кешеләргә кеше психикасының сәләтләрен күрергә мөмкинлек бирә. Илшат әйтүенчә, азакта, үзен гафу иткән, барлык психологик процессларны узган Микулай оҗмахка эләгә. Моны ишеткәч, гаҗәпләндем. Психологик яктан, бу мөмкин хәл түгел. Әлбәттә, иҗат төркеме могҗизага урын калдырган. Микулайга мин шизофрения диагнозы куям. Бу чирдән тулысынча котылып булмый. Хәтта дарулар ярдәмендә дә, – дип сөйләде Алия Булатова. – Шизофрения белән туалар. Тышкы вакыйгалар чиргә йогынты гына ясый ала. Минем өчен бу фильм үзеңә карата булган мәрхәмәт турында. Герой даими газап халәтендә. Тамашачыны да үзләренә карата мәрхәмәтле булырга өнди.

Клиник психологның фәнни тәгълиматлары пьеса авторы Мансур Гыйләҗевкә бик үк ошап бетмәде. «Бала»сына кагылышлы сүзләргә аның да җавап бирәсе килде.

– Мин, дөресен әйткәндә, шокта. «Микулай» – минем «бала»м. Аның образы белән мин яшәдем. Аны шизофреник, авыру дип әйтүләрен ишетү минем өчен кыен һәм шакаткыч. Бу бер дә җитди түгел, – диде ул. – Минем өчен Микулай – игелекле, дөрес кеше. Ул – бала туу, үлем, сугыш һәм тынычлык кебек дөнья төзелешенең төп законнарын саклап калырга тырышучы. Мондый кешене авыру дип санарга буламы?

Илшат Рәхимбайның исә каршы җавабы бар булып чыкты:

– Без шундый дөрес кешеләрне шизофреник дип атый торган тиле дөньяда яшибез түгелме соң? – диде ул.

…Иҗат төркеме максатына ирешкән булып чыга, димәк? Һәркем «Микулай»дан үзенә кирәген тартып чыгарачак, үзенә кагылганын күрәчәк. Психолог теле белән әйтсәк, фильм «триггер» (нинди дә булса гамәлне башлар өчен этәргеч. – **Авт.**) функциясен үтәде бит. Үтәмәсә, битарафлар күп булыр иде. «Микулай»га битараф калган кеше булмады. Тик үпкәләүчеләр күбрәктер, бәлки.

Ләйсән САФИНА,
Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, милли гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

РУС

Казан

ОМТЫЛЫШ

Сәхифәбезнең исеме дә, җисеме дә телгә бәйле булганлыктан, Казанда яшәүче, «Без тарихта эзлебез» бәйгесендә җиңү яулаган Ярцев-Лозовойлар гаиләсе белән сүзебезне шул тирәдән башладык. Кайчагында социаль челтәрләрдә: «Рус телен саклап калырга кирәк, телебез бетә!» – дип чаң сугучылар очраштыргалап куя. Шушы хакта фикерләрен беләсем килде. Әңгәмәдәшем, Казандагы 81 нче мәктәпнең директоры Антонина Алексеевна башта хәтта аптырабрак та калган кебек булды.

– Ничек инде алай дип әйтергә мөмкин? – диде ул. – Мин республикабызда рус теленә бернинди хилафлык күрмим. Булганы да юктыр дип уйлыйм. Россия составында булгач, сәясәтебез дә шулай корылган бит инде. Киресенчә, күрүемчә-белүемчә, башка милләт вәкилләренә кыенрак булган чаклар бар. Директор буларак, мондый очракларда үзем дә ярдәм итәргә тырышам. Безнең мәктәптә күп кенә рус балалары туган тел итеп татар телен сайлый. Рус телен өйрәнү буенча проблема юклыгын алар яхшы аңлый бит. Бу очракта тугандаш телне әйбәтрәк өйрәнәселәре килә. Сәбәбе шул. Әмма камиллеккә чикләр юк. Анысы инде үзебездән тора. Мәсәлән, без беренче чиратта телебезнең чисталыгы өчен көрәшергә тиеш. Мин бу очракта чит телләрдән кергән сүзләрне бөтенләй төшереп калдыру турында әйтмим. Әмма һәр нәрсәнең чамасы булырга тиеш. Бу рус теле өчен генә түгел, башка телләр өчен дә шулай дип аңлыйм. Сүз дә юк, телне үстерү белән төрле яклап, гел шөгыльләнеп тору кирәк. Бер яктан караганда, бу күбрәк фән белгечләренә кагыла кебек. Әмма һәрберебез үз өлешен кертергә тиеш. Бу эштә гаиләбезнең шактый гына катнашы бар дип саныйм. Шәҗәрә бәйгесендә катнашырга уйлагач, ирем Дмитрий белән архив дөньясына кереп чумдык. Ә андагы документлар белән танышу өчен иске рус телен өйрәнергә туры килде. Бу – үзе үк зур хезмәт бит, ирем кебек информатика, технология өлкәсендә эшләгән кеше өчен бигрәк тә. Хәзерге телдән әллә ни аермасы булмаса да, искесен укыр өчен шактый гына вакыт күнегергә кирәк. Сеңлем Екатерина, мәсәлән, чиркәү хорында җырлый. Алар борынгы җырларны, шуның белән бергә тарихны өйрәнәләр. Монысын да рус телен камилләштерүдә саллы гына өлеш кертү дип аңлыйм.

Чын дуслык

Антонина Алексеевна татарча да яхшы белә. Аның яшәү рәвеше шундый: җай, теләк булганда, бер яңалыктан да баш тартмаска. «Башка телләрне белү беркемгә дә комачауламас иде. Татарстанда күп төрле милләтләр яши. Безгә бергәләп эшләргә, бер-беребезнең телен, гореф-гадәтләрен хөрмәт итәргә кирәк», – ди ул. Шулай әйтергә җирлек тә бар. Ярцев-Лозовойлар – үзләре дә чын мәгънәсендә интернациональ гаилә. Дус, тату булып яшиләр. Санкт-Петербургтагы политехник университетта белем бирүче кызлары Алена белән Лобачевский исемендәге лицейда укучы Татьяна хәтта шәҗәрә бәйрәмендә дә татар кызлары булып киенгәннәр. «Кечкенәдән «Сәләт» лагерена йөрделәр. Икесе дә бик яхшы сөйләшә», – ди әниләре.

Аңлашыла ки, мондый сәләт «Сәләт»тән генә килмәгән. Бер гаилә эчендә төрле милләт халкы булгач, телне дә, гореф-гадәтләрне дә саклап, хөрмәт итеп яшәргә өйрәнгәннәр. Иң мөһиме, алар бу хакта беркайчан да онытмыйлар. Моңарчы билгеле булмаган туганнарын да әледән-әле эзләп табып торалар.

Ирле-хатынлы Антонина белән Дмитрий Ярцевлар төзи башлаган шәҗәрә агачында бүген 10 буын, 1100 кеше бар. Ярцев һәм Соловьевлар фамилиясе беренче тапкыр Казан губернасында, Чистай өязенең Иске Чишмә авылы янындагы чиркәүдә сакланган 1781 елгы язмаларда очрый. Лозовой фамилиясеннән булган тармак исә Тула өлкәсеннән башлана. Көнчыгыш халыкларына, белорусларга, казакларга барып тоташкан тармаклар да бар.

Педагоглар династиясе

Бу гаиләнең актив булуына, бәйгедә җиңеп чыгуына, бер караганда, гаҗәпләнәсе дә юк кебек. Укытучылар күп бу нәселдә. Санап та чыгарганнар. Педагоглар династиясенең эш стажы аз да түгел, күп тә түгел – 927(!) ел. Ә мөгаллимнәр булган җирдә, үзегез беләсез, тормыш аеруча кайнап тора. Дөрес, алар арасында да төрле һөнәр ияләре бар: балалар бакчаларында тәрбиячеләр, өстәмә белем бирү белгечләре, мәктәпләрдә, көллиятләрдә, югары уку йортларында белем бирүчеләр… Исемлектә җәмгысы 39 кеше. Иң күп стажлысы – ерак әбиләре Соловьева (Ольховик) Виктория Фоминична. Ул 52 ел буена башлангыч сыйныф укытучысы булып эшләгән. Башта Белоруссиянең Могилев өлкәсендә, аннан Татарстанның – Иске Чишмә, Түбән Каманың 10 нчы мәктәбендә. Арада «Атказанган мәгариф хезмәткәре» исемен йөртүчеләр дә, орден-медаль белән бүләкләнүчеләр дә байтак.

Педагог һөнәре гаиләнең үсешенә нинди йогынты ясый? Антонина белән шул хакта сөйләшәбез.

– Гаилә һәрвакытта да терәк һәм үрнәк булырга тиеш. Тәрбия бирә белүгә бик күп нәрсә бәйле. Әти-әниләреннән күреп, балалар укытучы һөнәренә тартыла икән, бу инде – тайпылмыйча, туры юлдан барабыз дигән сүз. Дөресен генә әйткәндә, мәктәптә укыган елларда укытучы булу теләге юк иде минем. Техник югары уку йортын тәмамлап, фәнни эшләр дөньясына чумдым, Казан химия-технология институтында укыта башладым. Әмма күңелем, нишләптер, гел мәктәпкә тартылды. Бу хисне мин әнә шул нәселебездәге династиягә бәйлим. Татарстан Республикасының «Яңа укытучыбыз – 2011» бәйгесендә катнаштым да җиңү яуладым. 2011 елдан бирле – мәктәптә, 2016 елдан – директор урынбасары, 2021 елдан – директор. Арабызда педагоглар династиясен дәвам иттерүчеләр байтак: сеңлем Екатерина вокал-хор дисциплиналары буенча укыта, туганнарым Алексей белән Александр, тагын бер кыз туганым Ирина да – педагоглар. Шушы һөнәрне сайлаган туганнарыбыз бик күп. Династиянең географиясе дә бик киң: Казан, Түбән Кама, Иннополис, Балтач, Яшел Үзән, Мәскәү, Березники, Пермь, Вязники, Ашхабад… Алар барысы да рус теле белән бергә нәсел-нәсәбебездә булган башка милләт вәкилләренең телен дә, гореф-гадәтләрен дә кадерләп саклыйлар.

НӘСЕЛ ГОРУРЛЫГЫ



– Без бигрәк тә ерак бабабызның абыйсы **Владимир Петрович ЛУШНИКОВ** белән горурланабыз. Ул – Казандагы «Органик синтез» предприятиесенең беренче директоры, Социалистик Хезмәт Герое. Хәзерге вакытта башкалабызның бер урамы һәм нефть химиясе көллияте аның исемен йөртә, – дип сөйли Антонина Алексеевна. – Әйтергә кирәк, ул да үзенең хезмәт юлын гади укытучыдан башлый: 1930 елда Питрәч районының Скородумовка авылында башлангыч сыйныфларны укыта. Бер елдан шушы мәктәпнең директоры була. Соңрак аны «меңчеләр» исемлегенә кертеп, югары белем алу өчен, Казан химия-технология институтына җибәрәләр. Укуны тәмамлагач, ул предприятиедә эшли башлый да тиз арада директор дәрәҗәсенә күтәрелә. Абыебыз тәҗрибә уртаклашу өчен Германиядә, Япониядә була. Россия буйлап белгечләр эзли. Тәҗрибәсе зур, үзе һәркемгә үрнәк була.

Тәмле ризыклар

- Гаиләбезнең иң яраткан ризыгы – өстенә шикәр комы сибелгән **алма пирогы**. Аның рецептын 1941 елда Волгоградтан эвакуацияләнгән ерак әбием Екатерина Ивановна алып кайткан. «Мәскәү грушевкасы» дип аталган сорттан эчлек бик тәмле була. Өстенә шикәр комы сипкәндә, ваниль белән корица кушарга онытмаска кирәк.
- Өстәлебездә еш кына белорус ризыклары да урын ала. Ул рецептларны әбиебез Виктория Фоминична Татарстанның Иске Чишмә авылына сугыштан соң алып килә. **Эчлеген** әзерләү өчен, өй шартларында ясалган эремчек һәм каймакка ваниль, йөзем кушалар да килеп чыккан массаны беленгә төрәләр, духовкада кыздырып алалар.
- Ә **үзбәк пылавын** әзерләү рецептын Балтачка минем каенанам Наилә Фәритовна Наманганнан алып кайткан. Укучыларыбызга бер серен дә ачабыз. Пылауга дөге белән кишерне тигез күләмдә салырга кирәк. Шул вакытта ул аппетитны уятырлык алтынсу төскә керә. Тәмләткечләрдән исә кумин-зира, кашнич, паприка, рәйхан, куркума салабыз.
- Татар милли ашларын пешерергә дә мине каенанам өйрәтте. Гаиләбездә хуш ис килеп торган **пәрәмәч һәм кош телен** бик яратып әзерлибез.

ТАБИГАТЬ КОЧАГЫНДА

Җәй көне гаиләбез белән урманга йөрергә яратабыз. Кара җиләк, җир җиләге җыябыз. Бакчабызда сырганак, карлыган, чия, слива, кура җиләге үстерәбез. Аларны төрлечә кулланабыз, төрлечә эшкәртәбез. Әмма тормыш үз кагыйдәләрен кертми калмый. Соңгы вакытта җиләкләрдән чәй өчен шарчыклар әзерли башладык. Башта без аларны формага салып катырабыз да аннан пакетларга салып куябыз. Җәйге озын кичләрдә мондый витаминлы чәйләр – җан рәхәте.

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде.
Фотолар гаилә архивыннан

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 310

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+